БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД ПОДДЕРЖКИ СОЦИАЛЬНОГО РАЗВИТИЯ
ГО Г. АГИДЕЛЬ РБ

ЛИТЕРАТУРНОЕ ОБЪЕДИНЕНИЕ «АГИДЕЛЬСКИЕ РОДНИКИ»
ПРИ МАУК «ЦЕНТРАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА ГО Г. АГИДЕЛЬ РБ»

# ЛИТЕРАТОРЫ Агидели 2




2018

БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД ПОДДЕРЖКИ СОЦИАЛЬНОГО РАЗВИТИЯ
ГОРОДСКОГО ОКРУГА ГОРОД АГИДЕЛЬ РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН

ЛИТЕРАТУРНОЕ ОБЪЕДИНЕНИЕ «АГИДЕЛЬСКИЕ РОДНИКИ»
ПРИ МУНИЦИПАЛЬНОМ АВТОНОМНОМ УЧРЕЖДЕНИИ КУЛЬТУРЫ
«ЦЕНТРАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА ГОРОДСКОГО ОКРУГА ГОРОД АГИДЕЛЬ
РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН»

# ЛИТЕРАТОРЫ Агидели 2

альманах

ИЗДАТЕЛЬСТВО «ЧУРАГУЛ»
УФА • 2018

Каждый уголок России славится талантливыми людьми, чье творчество согревало и согревает души людей, помогая жить, работать, плакать и петь на всем нашем жизненном пути. Убедительное тому подтверждение — созданное в 2011 году литературное объединение «Агидельские родники». Оно продолжает набирать обороты: уже издан один альманах, также авторы самостоятельно издают свои книги.

Как незаметно летит время! Казалось, только недавно увидел свет первый выпуск альманаха «Литераторы Агидели». С тех пор прошло четыре года. За это время многое изменилось. Одни литераторы продолжают писать, другие поменяли место жительства, пришли новые, и, к большому сожалению, есть и те, кто покинул этот мир.

Гордость Агидели, автор многих книг, изданных в центральных издательствах, Юрий Шурупов принят в Союз писателей России и Республики Башкортостан. Рамзина Тимерова, известная как автор многих песен не только в Башкортостане, но и в соседних регионах, издала книгу «Гомерләр балкышы».

Наши поэты ведут активный образ жизни. Недавно они успешно выступили на Межрегиональном литературно-поэтическом фестивале-конкурсе устного творчества «Ата-бабалар ауазы» («Зов предков»), который проходит в селе Николо-Березовка Краснокамского района раз в три года. Так, Милауша Вахитова стала обладателем диплома лауреата III степени в номинации «Поэты-публицисты», а Найля Каримова и Манзиля Сулейманова были отмечены дипломами участников и памятными сувенирами.

И вот, назрела необходимость издания второго выпуска альманаха. Это стало возможным благодаря победе Благотворительного Фонда поддержки социального развития городского округа город Агидель Республики Башкортостан в конкурсе социально ориентированных некоммерческих организаций Республики Башкортостан в целях предоставления им субсидий из бюджета Республики Башкортостан на возмещение или на финансовое обеспечение затрат по реализации общественно значимых программ. В смету расходов общественно значимой программы «Островок женского общения» включено финансирование издания второго выпуска альманаха «Агидельские родники». Это поможет нашим литераторам раскрыть свой творческий потенциал, а читателям Агидели и Прикамья в целом — поближе узнать о своих талантливых земляках, проникнуться творчеством, наполненным любовью к своему родному краю.

Есть что-то такое в нашей природе, в ее лесах и лугах, что заставляет человека мыслить и говорить поэтическими образами. Богат наш башкирский край талантливыми людьми! Нет, не исчезнет никогда живой родник народной души! А всем нашим литераторам мы вновь пожелаем, чтобы вдохновение их не покидало!



# БАГМАНОВА
## НУРАНИЯ МУКАТДАСОВНА

Багманова Нурания Мукатдасовна родилась 26 ноября 1962 года в деревне Балыклыкуль Аургазинского района Республики Башкортостан. В 1980 году окончила школу, поступила в ПТУ в г. Стерлитамаке. Получила специальность декоратора мебели. Трудовую биографию начала на мебельной фабрике в г. Уфе. Некоторое время работала в ПШО «Мир». Первое стихотворение написала в 1982 году. В г. Агидель живет с 1990 года, работает в городской больнице. Печатается в местной прессе.

## ИЛАТМАҒЫҘ ҠАЙЫНДАРҘЫ

Оло ялан... Ялан уртаһында
Яңғыҙ ҡайын түгә йәштәрен.
Яндарында түңгәк кенә ҡалған,
Ҡайһы рәхимһеҙе ҡул һалған?

Яҙҙар еткән һайын пар ҡайының
Кейә ине йәшел күлмәген.
Кемдәр генә уға һоҡланмаған,
Кемдәр генә башын эймәгән?

Бөгөн килеп, ошо аҡ һылыуҙың
Йөрәгенә яра һалғандар.
Яра ғына һалып ҡалмағандар,
Ярты йәнен тартып алғандар.

Ялан уртаһында бер яңғыҙы
Күпме генә йәшәр ҡайының?
Юғалтҡан шул парын инде хәҙер,
Кемгә генә һөйләр серҙәрен?

Көслө ел-дауылдар ҡупҡан саҡта,
Һыйынырға пары ҡалмаған.
Илатмағыҙ, зинһар, илатмағыҙ,
Яҙҙар еткән һайын ҡайынды!

## ҠАЙҘА ҺИН, ДӨРӨҪЛӨК?

Ниңә генә ерҙә дөрөҫлөк юҡ,
Шәфҡәтһеҙлек баҫҡан донъяны?
Ниңә генә ҡылған яҡшылыҡтар
Гел яманлыҡ булып ҡайталар?

Тирә-яҡты ҡарап тормайҙар шул,
Уңды-һулды айыра белмәйҙәр.
Күккә сөйәләр ҙә морондарын,
Онотола ҡалған эштәре.

Бер ни тормай ундай кеше өсөн
Рәнйетеүе юҡҡа кемделер.
Аллаҡайым тимәй, сабыр итәм тимәй,
Бер хәлһеҙҙе таптап үтәлер.

Күҙҙәремдән мөлдөрәп йәштәр аға.
Ниңә ошо тиклем һынауҙар?
Кемдәр яуап бирер был һорауға?
Ҡайҙан табып була дөрөҫлөк?

Аллаҡайым тимәҫ, туҡтап сәләм бирмәҫ,
Иҫтәренә төшөр бер ваҡыт.
Байлыҡ бит ул бары тик бер айлыҡ,
Кеше булып ҡала беләйек.

## ӘФГАНИСТАН

Әфганистан, күпме яшь балалар,
Куенында ятып калдылар.
Тар юлларың, биек тауларың —
Алар бары шаһит булдылар.

Газиз аналарның күзләрен
Томалады әче күз яше.
Иң авыры бала хәбәре,
Күтәрерме ана йөрәге?

«Әнием, бәгърем, син кайгырма», —
Дип хат язган бала анага.
Язган хатның юлы озын булды —
Аны укыганда
Кисек иде солдат гомере.

Бала чагы үтте күз алдыннан,
Агач мылтык иде кулында.
Яңа казып куйган җир өстенә
Уштан язып ана егылды.

Эшелоннан төшә яшь балалар,
Күзләрендә Әфган тузаны.
Ил алдында алар бурыч үтәп,
Тугры калган биргән антына.

Түгелмәсен иде күз яшьләре,
Еламасын иде аналар.
Аяз күкнең, илнең тынычлыгын
Капламасын кара болытлар.



# ВАХИТОВА
## МИЛАУША ФИНАТОВНА

Вахитова Милауша Финатовна родилась 20 марта 1964 года в деревне Бургунбаш Татышлинского района Республики Башкортостан. Среднее образование получила в деревне Курдем родного района. Окончила филологический факультет Бирского государственного педагогического института. В Агидели живет с 1991 года. Работает воспитателем в детском саду.

Ее стихи увидели свет в республиканской прессе: в журнале «Толпар» и в газете «Диляфруз».

В Межрегиональном литературно-поэтическом фестивале-конкурсе устного творчества «Ата-бабалар ауазы» («Зов предков») в номинации «Поэты-публицисты» стала обладателем Диплома лауреата III степени.

## АК ЮЛ СЕЗГӘ, КОШЧЫКЛАРЫМ!

Ял көннәре үтеп тә китте. Ике көн эчендә сагынып та өлгергән кошчыкларым янына сөенә-сөенә эшкә ашыгам. Мин килеп керү белән бер-берсен бүлдерә-бүлдерә хәбәрләрен сөйли башларлар. Шулкадәр ягымлы, шулкадәр сөйкемле алар!

Тик берсе аз гына шуграк, икенчесе чак кына тәртипсезрәк, өченчесе гел уйчан… Ә нигә уйчан? Әтисе еш кына эчеп кайта, әнисен, туганнарын — барысын да өйдән куып чыгара. Ник шушы биш кенә яшьлек баланың да башларына авыр сагышлар төшә икән?

Ә берсе шулкадәр бәхетле! Шатлыгының чиксез икәнен сизеп, башкаларны азрак кыерсытып алырга да җитешә. Ә мин кыерсытырга юл куймаска тырышам. Бер-берсе белән дус, тату яшәргә өйрәтәм. Бакчадагы вакытлары бәхетле үтсен, дип тырышам.

Мин аларны гына түгел, алар үзләре дә мине тәрбияли. Бервакыт нәрсә өчендер бик кызып китеп тирги башладым. Араларыннан бер кыз: «Апа, ә Сез шундый матур!» — дип әйтеп ташламасынмы?! Бу сүзләр мине шып туктатты да, үземнең ялгышуымны, сабыйларга беркайчан да тавыш күтәрергә ярамаганны искәртте. Әй, гөнаһсыз сабыйларым! Менә сезнең белән аерылышыр чак та килеп җитәр. Барыгыз да сөенә-сөенә мәктәпкә китәр. Тормыш дигән олы үзәннәрдә берегез дә адашмыйча, һәрберегез үз юлын табып, үз сукмагын салып барсагыз иде! Нечкә генә канаткайларгыз беркачан да сынмасын! Ак юл сезгә, кошчыкларым!

## КӨЗГЕ САГЫШ

Салкын көзнең сары сагышы бар,
Күңелләргә кереп сарыла.
Йөрәктәге әрнү-сагышларым
Күз яшьләре булып агыла.

Көзләр моңсу, шулкадәрле моңсу,
Табып булмый һичбер дәвасын.
Үкенмичә үтеп булсын иде
Язлар белән көзләр арасын.

## ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ БУЛСЫН ИДЕ

Язмышлардан узмыш булсын иде,
Булсын иде язмыш үзгәртеп.
Барыр юлларыңны алдан күреп,
Атлар адымыңны күзәтеп.

Туры юлдан гына атлап барып,
Алдар сукмакларга борылмый,
Ялгышмыйча, адашмыйча гына
Нигә икән алай барылмый?

Балаларым, бәгырь җимешләрем,
Тормыш юлы бигрәк катлаулы.
Кайчаклар да бигрәк авыр була
Җил-давылга каршы атлавы.

Язмыш сезгә мәрхәмәтле булсын,
Күңел халәтләрен аңласын.
Бәреп-сугып сезне сынамасын,
Кайгы-сагышлардан сакласын!

## МИН КҮРӘСЕН БЕРКЕМ КҮРӘЛМИ

Телең усал диләр, түгел иде,
Яши-яши дөнья өйрәтте.
Әйткән сүзләремне аңламыйча,
Йөзе белән тормыш түләтте.

Тау башына менеп җиттем дисәм,
Башларыма сугып төшерде.
Тырышып-тырышып алга үрмәләргә,
Күтәрелергә дә көч бирде.

Минем гомер — кешенеке түгел,
Мин үтәсен беркем үтәлми.
Ходай биргән язмышларны кичми,
Бу дөньядан һичкем китәлми.
Мин күрәсен беркем күрәлми.

## ЯШИК ӘЛЕ ЯШЬНӘП

Еллар авыр елга карасаң,
Юллар авыр юлга күз салсаң.
Яшәү авыр бөтен көчең салып,
Яшим диеп яшьнәп яшәсәң.

Яшик әле яшен кебек яшьнәп,
Эштә эшлик бөтен көч салып.
«Шундый уңган, житез әле», — диеп,
Яшьләр көнләшсеннәр таң калып.

Җанга дәва балаларым минем,
Әткәй-әнкәй әле исәннәр.
Авыр чакта ярдәм кулы суза
Якыннарым, дуслар, иптәшләр.

## ЧӘЧКӘЛӘР БИТ ТОРМЫШ БИЗӘГЕ

Чәчкәләр бит тормыш бизәкләре,
Җанга дәва, күңелгә сихәт.
Агы, алы, күге, зәңгәрләре…
Үсә алар дөньяны ямьләп.

Кешеләр дә чәчкәләргә охшаш,
Берсе тыйнак, бик-бик кечкенә.
Таҗлары да бик үк купшы түгел,
Ераклардан янмый гел генә.

Ә кайберсе бигрәк назлыбикә,
Караганны бик тә ярата.
Чәчкәләр дә хуш ис тараткандай,
Тирә-якка ямьнәр тарата.

Ә кайберсе бигрәк инде олы,
Тирә-якны каплый, шашына.
Тик мин генә гөлләрнең гөле дип,
Агуларын чәчә, ашкына.

Агу чәчми, ямьле итеп яшик,
Дөньяларда булсын татулык.
Матур чәчкәләрдәй матур булыйк,
Тудырыйк без җирдә гүзәллек!

## СОКЛАНАМЫН ХАЛКЫМ ЯЗМЫШЫНА

Башкорт кызы үзем, татар теле —
Туган телем туа-тумыштан.
Саф татарча әнкәем җырлары
Эз калдырды минем язмышта.
Бабаларым яуда ятып калган
Азатлыкка юллар ярганда.
Әткәм киңәшенә колак салам
Юлларымда арып калганда.
Көчле рухлы булган батыр халкым,
Баш имәгән явыз дошманга.
Яшь буынга тәрбия биргәндә
Салаватым тора күз алда.
Сокланамын халкым язмышына,
Сыкранмаган авыр чакларда.
Башкорт рухын саклар оныкларым,
Сөйләшерләр татар телендә.

## АНА КҮҢЕЛЕ МӘҢГЕ БАЛАДА

Ике бәхет кошым очып китте,
Аерылдылар туган оядан.
Кошларга да шулай авыр микән
Аерылуы газиз баладан?
Матур булсын тормыш юлларыгыз,
Эшләрегез һәрчак уң булсын!
Туры юлдан атлап барыгыз сез,
Янызда тугры дус булсын!
«Ике бәхет кошым, ике алмам,
Ике йөрәк парәм — ике балам,

Берүк исән йөрегез сез», — диеп,
Озатканда теләк теләп калам.
Минем теләк сезне саклап йөртсен
Авырлыктан, чирдән, куркудан.
Туган йортта һәрчак ана күтә
Арчаларга сагыш, борчудан.
Адашмагыз тормыш юлларында —
Изге теләк тели һәр ана.
Бала күңелләре кайда икән?
Ана күңеле мәңге балада!

## ЯКТАШЫМ ГӨЛНАЗГА

Без бит әле тәтешлеләр —
Урман ягы, тау ягы.
Үзәктән ерак булсак та,
Төшеп калган юк әле.
Төпкелләрдән чыга бит ул
Кешенең асыллары.
Безнең якны да зурлаган
Асыл затлар бар әле.
Гали Чокырый авылын
Син һәрвакыт узасың.
Хәния Фәрхи җырларын
Син сагынып сузасың.
Салаватның сәхнәсендә
Син дә чыгыш ясаган.
Атнабайның мәктәбендә
Мин дә белем алалган.
Ходай биргән тормыш йөген
Без бик тырышып тартыйк.
Бөек якташларыбыздан
Һәрвакыт үрнәк алыйк.

## ӘТКӘЙГӘ

Һәрчак сабыр булдың, әткәй, безгә
Мәрхәмәтле, изге күңелле.
Тыныч кына дөнья көтәсең син,
Бул син безнең озын гомерле.
Таза-исән булып, кайгы күрми
Яшә әле, әткәй, йөзгәчә.
Сирәк-мирәк авыртынсаң да син,
Атлауларың әле яшьләрчә.

## ӘТКӘЙГӘ

Җаның тыныч булсын, тәнең таза,
Әткәкәем, әткәм, кадерлем.
Әнкәй белән тигез гомер кичер,
Булыгыз сез озын гомерле.
Бик күп еллар язсын әле сезгә
Йөгерә-йөгерә дөнья көтәргә.
Шатлык-куанычлар белән генә
Гомер юлын бергә үтәргә.

## ӘНКӘЙГӘ

Чәчләреңнең күпме өлешендер
Мин бит, әнкәй, синең агарткан.
Күпмесендер апа, күпмесендер энем,
Ә шулай да, без бит синең — иң-иң яраткан.
Чәчләреңне, әнкәй, агартсак та,
Без бит хәсрәтеңне тараткан.
Сөенеч тә, көенеч тә итеп

Ходай безне шулай яраткан.
Чәчләремнең хәзер карасы аз,
Күп өлеше инде агарган.
Күпме сагыш, борчылулар белән
Бер-бер артлы еллар агылган.
Күпме шатлык, сөенечем минем —
Ике балам — ике багалмам.
Чәчләремнең күпме өлешедер
Сезнең өчен генә агарган?
Чәчләребез безнең агарса да,
Хәсрәтебез шулай тарала.
Бәхет, шатлык янәшә булса да,
Кайгылар да кереп урала.

## ӘНКӘЕМНЕҢ ЙӨРӘГЕ

Әнкәемнең йөрәгенә
Сыйган бөтен изгелек.
Күңеле нур чәчеп тора,
Кылганы — тик игелек.
Карт көнеңдә, әнкәкәем,
Яшәсәң иде рәхәт.
Кылган һәрбер изгелегең
Кайтсын үзеңә кабат.
Санап бетерерлек түгел
Синдәге яхшылыкны.
Жиңеп һәрвакыт киләсең
Юлыңда каршылыкны.
Әнкәй, безгә һәрвакытта
Булырсың бик кадерле.
Бәхет, шатлыклардан торган
Бул син озын гомерле!

## ТУГАН АВЫЛЫМ

Туган авылым, сине сагынып кайтам,
Туган өем, туган җиркәем.
Әткәй, әнкәй йөгереп каршы ала
Сагынып көткән газиз бәбкәен.
Туган якның сулары да шифа,
Җилләре дә бигрәк ягымлы.
Бар да миңа монда бигрәк якын,
Күршеләрем бигрәк кадерле.
Ялантәпи йөргән тыкырыгым,
Сандугачлы чишмә буйлары.
Балачакка, туган якларыма
Әйләнә дә кайта уйларым.
Җир җиләге җыйган тау буйлары,
Печән чапкан иркен болыннар,
Ашлык үскән иксез-чиксез кырлар,
Без утырткан чыршы, каеннар.
Барысын да тагын сагынып кайтам
Туган авылым, туган ягыма.
Ашкыныплар, йөгерә — атлап барам
Әткәм белән әнкәм янына.

## ГҮЗӘЛЛЕГЕН САКЛЫЙК ТУГАН ҖИРНЕҢ

Туган җирем, синнән матурырак
Нинди җир бар? Белмим мин әле.
Дөнья буйлап йөрдем, күпне күрдем.
Тик күрмәдем синдәй гүзәлне!
Челтер-челтер аккан чишмәләрем
Авылымны урап алганнар.

Зифа буйлы миләш, каеннарым
Мин киткәндә озатып калалар.
Сездән башка озак яши алмам,
Мин кайтырмын тагын сагынып.
Сездән җыеп илаһи бер көчне,
Мин яшимен сезгә табынып.
Таңга чаклы сандугачлар сайрый,
Барча галәм тыңлый таң калып.
Ярсу йөрәкләргә уйлар өстәп,
Күңелләргә сихри моң салып.
Урманнарга керсәң, исең китә
Матур-матур киек, бөҗәккә.
Туган якның шушы гүзәллеген
Саклыйк әле озак-озакка.
Чишмәләрне чиста итеп тотыйк,
Күкрәп чәчәк атсын болыннар.
Табигатькә сокланырлык булсын
Бездән соң да килгән буыннар!

## ТОРМЫШ ИПТӘШЕМӘ

Безне Ходай бергә кавыштырды
Уртак булсын диеп уйлары.
Бәхет, шатлык, сөенечләр белән
Матур үтсен тормыш юллары.
Үтеп китте инде егерме ел —
Бергә-бергә үткән гомерләр.
Күпме авырлыклар кичердек без,
Күпме шатлык, сөю, көтүләр…
Көтеп ала идек вахтадан без —
Сине көтеп үтте бу еллар.
Инде балалар да үсеп бетте,
Озын булсын уртак гомерләр.

## УЛЫМА

Сагыныплар көтеп алам синең
Армиядән кайтуларыңны.
Бигрәк авыр булды шушы бер ел,
Якынайтты картаюларны.
Картайсам да була инде хәзер —
Ике балам үсеп буй җитте.
Икегез дә игелекле булып,
Таянычым булсагыз иде.
Бәхеткәйләрегез бик күп булсын,
Акыл, тәүфыйк бирсен Ходаем.
«Бер-берегезгә терәк булыгыз», — дип,
Мин һәрвакыт сезгә телимен.

## КЫЗЫМА

Кызым, кызым, бәләкәчем минем,
Очар коштай янымнан очтың.
Очмас идең — хәзер вакыт инде,
Тормыш дулкыннарын син кочтың.
Һәр нәрсәнең үз вакыты була,
Тотып булмый гомер агышын.
Яктылардан якты йолдыз булып,
Киләчәгең синең балкысын!

## ГОМЕР КӨЗЕМ

Гомер көзем килеп җиткән икән,
Шуны аңлый алмый күңелем.
Нигә гел язлардан гына тормый
Бу дөньяда кеше гомере?

Акыл аңлый, акыл кабул итә
Язлардан соң көзләр булганын.
Күңел генә аңлап бетә алмый
Картаерга туры килгәнен.
Көзләрнең дә була төрле мәле:
Яңгырлары, усал җилләре.
Күңелемдә матур чуак булсын,
Тормышымда булса көзләре.

## КИТАП ҖЕНЕ КАГЫЛГАНДЫР

Китап җене кагылгандыр,
Укыдым кечкенәдән.
Бу һөнәрне ташларга дип
Уйламыйм һичкенә дә.
Биш яшем дә тулмаган да
Китапханәгә йөрдем.
Әтиемнең китапларын
Барысын укып бетердем.
Китапларны укый-укый,
Аң-белемнәр мин туплыйм.
Шигъри дәрьяларда йөзәм,
Хисләр дөньясын буйлыйм.

## КӨЗЛӘР, ҖӘЙЛӘР — БАР ДА БУТАЛГАН

Яшел язлардан соң көзләр килде,
Ямьле җәйләр әллә булмаган?
Җылы җәйләр ай-һай бик тиз үтә,
Күңелләрем аны туймаган?

Җәйләрем соң минем кайчан булган,
Нигә аны күңелем күрмәгән?
Әллә минем нечкә кылларымда
Күзләр, җәйләр — бар да буталган?..

## АККОШ КҮЛЕ

Аккош күле — очрашулар,
Күрешүләр урыны.
Алтмышка җиткәч тә сөю
Үзе серле түгелме?
Насыйп булгач, юл китерде
Тагын Аккош күленә.
Үлгәнче бергә булырга
Олы йозак эленә.
Күл буенда пар кошларны
Язсын бик еш күрергә.
Аккошлардай тугры сөю
Насыйп булсын гомергә.

## ҖАЙСЫЗ КЕШЕ

Җайлы булалмадым беркайчан да,
Уйлаганны туры әйтәмен.
«Кемгә ниләр әйттем бүген?» — диеп,
Үткәнемә кабат кайтамын.
Һәрбер әйткән сүзләремне уйлап,
Бизмәннәргә салып үлчимен.
«Гөнаһсызны рәнҗетмәдемме?» — дип,
Йөрәгемне кат-кат борчыймын.
Ә миңа соң дөрес әйтмәгәннәр

Уйлыйлармы икән шуларны?
Сүзләре бит җанга үтеп керә,
Телгәлиләр минем бәгырьне.
Таш бәгырьләр барыбер бер үкенер,
Ходай бар бит бездән олырак.
Астагылар өскә күтәрелер,
Биектәге төшәр тәгәрәп.

## ЯЗМЫШЫМ ЮЛЛАРЫНДА

Абаганың чәчкә аткан мәлен
Бик күп көттем, ләкин атмады.
Минем өчен сулар кире агып,
Кояш чыккан якта батмады.
Җаннарымны телеп-телеп ала
Гомеремнең ачы үткәне.
Үткән үткән инде көенсәң дә,
Хәерлегә булсын көткәне.
Җайлап кына язмыш юлларында
Борылышлар булсын уңайга.
Көзләр, кышлар, әле килмәгез сез,
Тукталыймча җәйге тугайда.

## ЙӨРӘК КЕЧКЕНӘ БУЛСА ДА

Йөрәк кечкенә булса да,
Барысы аңа сыйган.
Яхшысы да, яманы да
Үз урыннарын уйган.
Йөрәккәем, күпмеләргә
Син шулкадәр түзәрсең.

Вакыттыннан алдаракмы
Әллә соңрак тузарсың?
Йөрәккәем, таушалырга
Син бигрәк ашыкма.
Юкка-барга тузып барма,
Булмаганга ашкынма.
Бар да Ходай кушканча бит,
Көймәсәң дә, көйсәң дә.
Син күрәсен башка күрми,
Янып көлгә калсаң да.
Ходай бирсә — бар да булыр,
Булмый торса — сабыр бул.
Авырлыклар онытылыр,
Юк нәрсәләр табылыр.
Ходайкаем ярдәменнән
Ташламас беркайчан да.
Таза булыйк, исән булыйк,
Чирләмик һичкайчанда.

## ШИГЫРЬ ЯЗУ АВЫР ТҮГЕЛ

Шигырь язу авыр түгел
Чын күңелдән уйласаң.
Актарылып-актарынып,
Йөрәкләрне буйласаң.
Күңел түреннән чыга ул
Яңа-яңа куплетлар.
Кемнәндер көлеп аласың —
Бигрәкләр дә шәп бит әй!
Кемне үтереп мактыйсың,
Мактарлык җире булгач.

Кемне эт итеп тиргисең
Ачуың килеп киткәч.
Йөрәк ярсуы басыла
Кемнедер тиргәп алгач,
Кем беләндер сөйләшәсең,
Йөрәген ачып салгач.
Барысын да уйлап бирсәң —
Күңелгә сыешалмый.
Йөрәкләргә бар да сыймый,
Тулып ташыла башлый.
Ташылса ташылсын инде,
Биек ярлардан чыгып.
Шагыйрь булып булмас инде —
Атказанганы кебек.

## КҮБӘЛӘКТӘЙ
## АП-АК КАРЛАР ЯВА

Күбәләктәй ап-ак карлар ява
Сафландырып бөтен дөньяны.
Ап-ак карлар белән пакьлек керә
Нурландырып безнең җаннарны.
Ап-ак карлар ява — нинди матур!
Сихри нурга дөнья күмелә.
Җем-җем килә энҗе бөртекләре,
Бер-берсенә очып үрелә.
Табигатьнең нинди гүзәл чагы,
Кар астында йоклый далалар.
Кышлар белән кышлар арасында
Үтеп бетә алмас аралар...

## ОНЫТЫЛМЫЙ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ

Классташлар — якын иптәшләрем,
Ун ел бергә үткән дусларым.
Еллар үтү белән искә төшә —
Барчагызны искә аламын.
Араларда кайберләребез юк —
Кайчак хәбәр килә җилләрдән.
Йөгерә-йөгерә кайтып булсын иде
Кайтып булмый торган җирләрдән.
Бик күңелле итеп укыдык без,
Җиңел булды белем алуы.
Чөнки безнең алда һәрвакытта
Торды укытучы абруе.
Җиһан апа, Тәгъзимә апалар,
Фидәлия апа, Фәния апалар.
Тагын бик күп укытучыларым
Матур булып истә торалар.
Һәрберегез яхшылыгын бирде,
Булдыгыз бит бик мәрхәмәтле.
Изгелек һәм игелегегезгә
Барыгызга мең-мең рәхмәтле.
Классташлар — якын дускайларым,
Сез дә искә аласыз микән?
Бергә-бергә үткән сукмакларны
Онытырга мөмкинме икән?
Онытылмый мәктәп бусагасы,
Бәбкә үлән баскан алларын.
Еллар үтү белән онытылмас,
Хатирәләр тагын яңарыр.

## ГОМЕР БУЕ ҖАНЫМ НИДЕР ЭЗЛИ

Гомер буе җаным нидер эзли,
Ни җитми соң сиңа, күңелем?
Тормыш өчен кирәк бар нәрсәм бар,
Нәрсә генә җитми — мин белмим.
Үкенечләр йөрәкләрне телә,
Телгәләнеп йөрәк юккара.
Җаннарыма дәва каян алыйм?
Шул халәттән миңа юк чара.
Берчә дөрләп кабынам да китәм,
Очкыннары күккә үрелә.
Бер карасаң бигрәк бетеп китәм,
Сүнеп бетәм, сүнәм, сүреләм.

## МИНЕМ ЙӨРӘК

Минем йөрәк таштан ясалмаган,
Гап-гади бит, бик-бик кечкенә.
Авырлыклар йөрәгемә сыймый,
Сыймый икән, сыймый һичкенә.
Яшьләр булып сыкрап килеп чыга,
Елый туктамыйча, тилерә.
Яраланган йөрәк бәргәләнә,
Хисләр генә бары илерә.
Авырлыклар, килмәң инде миңа,
Ходайкаем, берүк кызган ла.
Көчлелеккә мине күп сынадың,
Җитәр инде, башка сынама.

## МИЛӘШКӘ

Миләшкәем, тагын бер ел үткән,
Нигә бик тиз үтә гомерләр?
Үтсә үтсен инде безнең гомер,
Олы байлык — безнең бу еллар!
Балаларның һәрбер адымына
Без сөенеп алга атлыйбыз.
Тирән дулкынлану хисе белән
Үткән гомерләрне барлыйбыз.
Үткәне дә үпкәләрлек түгел,
Нинди рәхәт җирдә яшәве!
Булганына шөкер кыла белеп,
Киләчәкнең алга дәшүе.
«Киләчәкләр сөенечкә күмсен,
Тазалыклар булсын янәшә.
Илләр имин булып, шат яшик», — дип,
Миләш дустың сиңа эндәшә.

## КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫЙК

Яхшылыклар жирдә ятып калмый,
Нигә яхшылыклар кылмыйбыз?
Яман холык, яман гадәт белән
Күңел пәрәләрен тырныйбыз.
Берәүләргә Ходай акыл бирә,
Икенчегә өеп акчалар.
Акылы да кирәк, акчасы да,
Үлеп китсәң — бар да калалар…
Берәү түрә булып китте исә —
Тирә-якта кешене күрми.

Күз алларын томан басып китә,
Кешеләрчә ул инде йөрми.
Бүре булып улый, эт тә була:
Кайдан күбрәк акча табарга?
Шундый яхшы итеп өйрәнә ул
Оялмыйча кеше таларга.
Берәү тыныч кына дөнья көтә —
Өлешенә төшкән көмеше.
Зур акчалар куып дуламый ул,
Талап алмый кеше өлешен.
Кеше булгач кеше булып калыйк,
Кырын эшләр тормышта кылмыйк.
Түрә булдык диеп бик масаймыйк,
Гөнаһсыздан кычкырып көлмик.
Бу гомерне сорап без алмаган,
Ходай бүләк иткән сөенеч.
Ничек итеп үтү безнең кулда,
Күнелләргә салмыйк үкенеч.

## КОШЧЫКЛАРЫМА

Бәләкәйдән сезне җыябыз да,
Талпынырга канат куябыз.
Кечкенә генә йөрәкләрегезгә
Мәрхәмәтлек уты уябыз.
Каршы алабыз да — гомер үтә,
Озатырга вакыт та җитә.
Матур булып үсеп җитәсез дә,
Барыгыз да мәктәпкә китә.
Фәрештәләр сезне саклап йөртсен
Тайпылдырмый туры юллардан.
Гомерегез матур итеп үтсен,

Торсын бары гүзәл гөлләрдән.
Нечкә генә канаткайларыгыз
Очкан чакта бер дә талмасын.
Тормыш дигән олы үзәннәрдә
Берегез дә адашып калмасын.



# ВЕСЕЛОВСКАЯ
## АЛЕКСАНДРА ФЁДОРОВНА

Родилась 28 октября 1986 г. в г. Благовещенск Республики Башкортостан. В 1987 родители привозят маленькую Сашу в город Агидель. Два учителя сыграли важную роль в судьбе Александры и дали возможность развиваться ей в качестве автора стихов: первая учительница Ахмадеева Фаниля Асватовна, которая привила юной Александре любовь к поэзии, рассказала о рифме, слоге, ритме и размере стиха и классная руководительница Мифтахова Флюра Факиловна, обратившая внимание на ее интересное хобби и поддержавшая ее стремление к поэзии, приглашая выступать со своими стихами в различных школьных и городских мероприятиях. В 2004 г. Александра заканчивает среднюю школу № 2 и поступает в Уральскую государственную Юридическую Академию г. Екатеринбург, где продолжает писать стихи и выступать с ними на различных вузовских мероприятиях.

Сменив ни одну должность и не одно место работы, Александра по-прежнему остается верна себе. Пишет стихи, путешествует по России, и получает удовольствие от работы. Любовь к горам стала источником вдохновения для многих ее произведений.

## ЗА ОКНОМ

Послушай, что ты видишь за окном,
Наверное, не то же что и я?
Людей, идущих хмуро под зонтом —
Им тоже одиноко от дождя.
Теперь представь, что ты не среди них,
Что их печаль не трогает тебя,
Ты веришь в ожидания других?
Ты знаешь, что они не для меня.
Рискни: опять представь себе меня,
Такую же свободную, как дождь.
Представь, что обнимаю вновь тебя,
Почувствуй, как бежит по телу дрожь.
Ты чувствуешь? Да, я дышу тобой,
Твоими мыслями, улыбкою, словами.
Дышу моей забытою мечтой,
Так быстро поделенной между нами.
Послушай, что ты видишь за окном,
Наверное, не то же что и я?
Двоих, идущих тихо под зонтом,
Поверь, они не чувствуют дождя.

## ЗАПУТАЛ

Ты запутал. А я? Заблудилась, наверно,
Средь пустых запорошенных дней.
Ах, как скверно, как все это скверно!
Не люблю я разбитых церквей.
А еще не люблю аромата гнилого,
И цветы на могилах друзей.

Не люблю, когда ценят кого-то другого,
Не того, кто достоин речей.
Не люблю оставаться в ответе
За себя и за тех, кто ушел.
Не люблю завывающий ветер
И речей лживых ласковый шелк.
Не люблю говорить о погоде,
Когда нечего больше сказать.
Не люблю, когда ценят в природе
Лишь того, кого могут поймать.
Не люблю целовать на прощанье открытку
И еще не люблю уходить.
Но сейчас я готова закрыть эту клетку.
Потому что так проще любить…

## КРИК ДУШИ

Прислушайся, и ты услышишь,
Как в тишине ночных витрин
Едва заметно сердце дышит,
Запутавшись в толпе причин.
Ты, заколдованный делами,
Бежишь навстречу суете.
Ты мог бы управлять мирами,
Жаль, их не видишь в темноте.
И ты скользишь по краю неба,
Так не заметив волшебства.
Тебе важней краюшка хлеба,
А не о ком поет листва.
Вновь в этом беге суматошном

Мой тихий стон не разобрав,
Ты вдруг решись: «Все понарошку».
И не поймешь, кто все же прав.
И за сверкающей обложкой
Никто из нас не различит.
Тот страх, что поселился кошкой
И песню сладкую мурчит.

## Я ПОКАЖУ ТЕБЕ МИР

Дай руку, и я покажу тебе мир
Таким, каким я его вижу весною:
Звенящий, наполненный песнями лир
И пахнущий яркой травою лесною,
Забытый, закруженный, скрытый от глаз,
Наполненный птичьими трелями,
Описанный парой запутанных фраз
И где-то раскрашенный елями.
Дай руку, и расскажу тебе сны,
В них нету порочной усталости.
В них воплощаются чьи-то мечты
И мелкие детские шалости.
Дай руку, и мы растворимся в ночи,
Она не предаст и укроет от страха.
Нам будет союзником пламя свечи,
Что, тлея, сжигает обиды до праха.
Дай руку, и я покажу тебе мир,
Таким, каким я его вижу весною:
Звенящий, наполненный песнями лир
И ярко расписанный мной и тобою.

## ДОТЯНИСЬ ДО МЕНЯ

Дотянись до меня, если сердце
охвачено стужей.
Дотянись до меня, не хочу оставаться одна.
Дотянись до меня, ты сегодня
как воздух мне нужен.
Дотянись до меня и достань
мою душу со дна.
Дотянись до меня, я так много
узнала о боли.
Дотянись до меня, мне нужна
теплота твоих глаз.
Дотянись до меня, даже если
расписаны роли
И тебе выпадает сыграть только
несколько фраз.
Дотянись до меня, когда хочется
скрыться навеки.
Дотянись до меня, когда некуда
больше бежать.
Дотянись до меня, усмиряя
безвременья реки.
Дотянись до меня, и скажи,
что ты будешь скучать.
Дотянись до меня на рассвете
в заснеженном парке.
Дотянись до меня, когда глупо
не верить словам.
Дотянись до меня, и в заветном
случайном подарке
Научи меня верить давно
позабытым мечтам.

## ВОСПОМИНАНИЯ О ШКОЛЕ

В кругу друзей, среди знакомых лиц,
Ты всё идешь по школьным коридорам.
И в дневнике, на каждой из страниц,
Расписаны все темы к разговорам.
Спеша решить задачек череду
И рассказать подругам о новинках,
Ты снова стих запишешь на бегу
И нарисуешь парня на картинках.
Звонок на перемену, на урок,
Задачи, теоремы, логарифмы,
Для сочинения вновь поставлен срок
И надо бы опять найти две рифмы.
Вот так проходит каждый школьный день.
Сменяются уроки переменой,
Ты через них проходишь, словно тень,
Мечтая стать взрослее и счастливой.

## ОБО МНЕ

Эта леди — сплошная загадка.
Словно кошка шагает в рассвет.
Балансируя, как акробатка,
Лично каждому скажет «привет».
В глубине её глаз пляшет пламя
И улыбка всегда на устах.
То безумно горда и упряма,
То как ангел парит в облаках.
Она верит в друзей, в их отвагу,
Называя их ближе родных.
За любого из них примет шпагу

И от пуль заслонит от шальных.
Она часто бывает несносна,
И, танцуя на самом краю,
Увернется от бурь виртуозно
И останется снова в строю.
Не согнут ее ветер и стужа —
Пусть стихия бывает строга.
Когда рядом с ней искорки кружат,
Не страшна никакая пурга.
«Эта леди — сплошная загадка», —
Кто-то скажет ей в след, чуть дыша.
А она улыбнется им сладко,
Даже если вся в ранах душа.

## ДОРОГА

Дорога снова будоражит мою кровь...
Ночь заполняет тишиною душу.
Я оставляю на пороге свою хворь
И покидаю проклятую ношу...
Она ведет знакомыми путями,
Мне открывая тайны горизонта,
Махая вслед ивовыми ветвями,
Кидает в лапы грозового фронта.
Дорога манит, требует движения.
Зовет туда, где, кутаясь в туман,
Я оставляю скорбь и сожаления
И признаю: свобода — не обман.
Она бросает мне навстречу ливни
И зной слепящих вышарканных трасс,
Она твердит, что примет только сильных.

О тех, кто тверд, она ведет рассказ.
Дорога — чистый лист для новой пьесы,
Пусть обо мне в ней лишь одна строка.
Я отыщу в пути лихие срезы
И посмотрю на тропы свысока.



# ГУМЕРОВА
## ГУЛЬНАРА ХАМИТОВНА

Гумерова Гульнара Хамитовна родилась 24 октября 1976 года в деревне Старая Мушта Краснокамского района. Закончив старомуштинскую среднюю школу, поступила в Башкирский государственный педагогический университет на факультет татарской филологии. После университета (2000 г.) работала учителем татарского языка и литературы в гимназии №115 (г. Уфа). Потом перебралась ближе к родителям и устроилась корреспондентом в районную газету «Кама таңнары». А теперь она главный библиотекарь в Новокабановской сельской библиотеке. Замужем. Вместе с мужем воспитывает двух прекрасных дочерей. В свободное время пишет стихи и сценарии.

## СУ АНАСЫ-2
## (ТУКАЙГА ИЯРЕП, МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН МАХСУС ЯЗЫЛГАН ЦИКЛ)

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коена, йөзә идем:
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзә идем.
Тик кызганыч, соңгы елда Кабан күле саекты,
Өсләренә яшел ләүшә һәм пычырак калыкты.
Балыгы да бик эләкми, утырасың биш сәгать,
Ә шулай да китеп булмый, канга бит сеңгән гадәт.
Бервакыт кайтам дигәндә, колакка килде тавыш,
Шул тавышка үрелгәндер ачы зар, моңлы сагыш.
— Ярдәм итче миңа, улым, булыш син миңа, оглан,
Су астында көчкә яшим, көчкә тын алып торам.
Су анасы дәшә миңа, ул миннән ярдәм сорый,
Ялвара, ялына миңа һәм дә үкереп елый.
— Начарланды хәзер кеше, бар чүпне күлгә ташлый,
Кайчан инде тәүбә итеп, баш белән уйлый башлый.
Әйдә мине бу сазлыктан тизрәк тартып чыгар,
Юкса монда тын кысыла, кем генә монда чыдар.
— Бир кулыңны, Су анасы, булышам сиңа сүзсез,
Торган урының бик начар — күрәдер хәтта күзсез.
Ай, рәхмәт, коткаручым, сокланып торам карап,
Хезмәтеңә бүләк итәм, ялтырап торган тарак.
Юк, кирәкми, бу тарактан мин бит көчкә котылдым,
Шул тарак бит аркасында карак булып тотылдым.
Хәзер мин бит ул эшләрдән бөтенләй читтә йөрим,
Баштан кичкән-үткәннәрне әкият итеп сөйлим.

## УТНЫ-СУНЫ КИЧКӘН УЛ

### (БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ Ш.ШИРИЕВ ИСТӘЛЕГЕНӘ)

Назламаган тормыш аны
Иркәләп кочагында.
Ашарына ризыгы да
Булмаган кайчагында.

Беркөн килеп өйләреннән
Урамга чыгарганнар.
Ач-ялангач булсалар да,
Түзгәннәр, чыдаганнар.

«Кулак» дигән авыр йөкне
Иңнәрендә тарткан ул.
Тырышлыгы аркасында
Үз бәхетен тапкан ул.

«Мулла малае» диеп тә,
Тәкърарлап торганнар.
Кайда гына барса да,
Аны кире борганнар.

Шәех абый бирешмәгән,
Максатка туры барган.
Үткәннәрдән үзенә
Ачы бер сабак алган.

Менә бүген, әйтерсең лә,
Бәхет көтә юлында.
Белем алыр, галим булыр —
Аттестаты кулында.

Әнә шулай хыялланып,
Очып йөргән чагында,
Өметләре челпәрәмә
Килде менә тагын да.

Явыз фашист бар нәрсәне
Җиргә салып тапады.
Кичәге егет һәм кызлар
Ил сагына атлады.

Шириев та — яу кырында,
Һаман алга ыргыла.
Әле танк өскә килә,
Әле пуля сызгыра.

Самолеттан бертуктамый
Бомба ыргыта дошман.
— Ашла! — диеп шушы җирне
Әйтерсең Ходай кушкан.

Чү!
Бар да тынды бер мизгелдә,
Тик башта нидер шаулый.
Дары исе һәр тарафта
Нәрсә бу? Аңлый алмый.

Һушын җуеп, ауды солдат,
Туфракка башын салды.
Юк, үлмәде Шәях абый,
Озак яткач, тын алды!

Карады ул як-ягына —
Юктыр һич адәм заты.

Кайда аның иптәшләре,
Кайда аның взводы?

Көчен җыеп шуышадыр
Алга, авылга таба.
Яраланган аягынннан
Туктамыйча кан ага.

Ә чишәргә ботинкасын
Һич солдат базнат итми.
Каршыда бит дәваларга
Шәфкать туташы көтми.

Ниһаять, авыл күренде,
Бер маяк булып уңда.
Безнекеләр, немецлармы —
Көтәдер аны монда?

Тын гына ятып күзәтте,
Ул куак арасыннан.
Елга төсле кан бөркеде
Сыкырап ярасыннан.

«Үзебезнең иптәшләр!» — дип,
Ярсып типте йөрәге.
Кабул булды солдатның да
Сугыштагы теләге.

Сталинград, Курск дугасы —
Шириев үткән юллар.
Кабатланмасын башкача
Дәһшәтле, авыр еллар.

Белсәгезме, күпме мина
Ташыган Шәях абый.
Днепрны да кичкән ул,
Һәм исән кайткан, ярый.

Әллә күлмәктә туганмы,
Исән-сау, җиңеп кайткан.
Күрәсең, туган авылы,
Кабан сулары тарткан.

Тыныч тормыш сагында да,
Һәрвакыт әйдәп барган.
Тарих битенә исемен
Олы хәрефтән язган.

Хәтер яши, тынгы бирми,
Төзәләдер яра да.
Онытмыйк яу кичкәннәрне —
Алар безнең арада.

## КУРЫКМЫЙБЫЗ!

Бәйрәм табыны янында
Ике әби серләшә.
Ике әби-ахирәт
Тәмләп кенә сөйләшә:

— Картлык-шатлык түгел, диләр,
Шатлык икән, ахирәт.
Пенсиябез килеп тора,
Безгә тагын ни кирәк?

Өстәлләрдә йомшак икмәк,
Агы һәм дә карасы.
Кирәк түгел кар — су ерып,
Симәнәгә барасы.

Авыр капчык, олы йөкләр
Басмыйдыр иңсәләргә.
Тормыш хәзер күпкә яхшы —
Ни генә дисәләр дә.

Кәлҗәмәләр эзләмибез,
Бәрәңге — түтәлләрдә.
Без күргәнне насыйп итмә,
Ходаем, бүтәннәргә.

Өс-башыбыз бөтен хәзер,
Интекмибез ачлыктан.
Килсен әйдә, курыкмыйбыз —
Каһәр суккан картлыктан!

## ЭХ, ПЕНСИЯ, ПЕНСИЯ

Пенсиягә чыгам диеп,
Бармакны бөгә торгач,
Ялга чыккач, моны эшлим,
Тегене дия торгач,
Үзгәрде китте закуны
Сизми дә калдым, чордаш.

Хәзер инде барлый калсаң,
Бармагы да җитмидер.

Каф тау артындагы ялны,
Беркем өзлеп көтмидер.

Үлгәнче эшлик дигәне,
Менә шул инде хәзер.
Җанны фида кылырга
Без бит ил өчен әзер.

Пенсия яшен үзгәртеп,
Яшәртәләр барысын.
Тик менә эш урыннарын
Белмим, каян табарсың?!

Кем генә сыер савар да,
Кем колхоз малын карар?!
Кирегә сөйләп тормыйм,
Покага җитте, ярар.

Үч итеп без яшик әле,
Йөздә дә гел яшь калыйк.
Пенсиясен түләттереп,
Дәүләтнең ушын алыйк.



# КАРИМОВА (ЯХИНА)
## НАЙЛЯ БАРЫЕВНА

Каримова (Яхина) Найля Барыевна родилась 23 октября 1952 года в городе Ревда Свердловской области в семье рабочего. Закончила юридический колледж. Профессия — юрист права и социального обеспечения. Долгие годы работала в системе социальной защиты населения г. Нефтекамска специалистом отдела кадров, позже — в налоговой инспекции. Неоднократно награждалась Почетными грамотами Министерства социальной защиты населения Республики Башкортостан, администрации г. Нефтекамска и военного комиссариата за многолетний добросовестный труд. Присвоено звание «Ветеран труда». С мужем воспитали дочь и сына. Теперь у нее пятеро внуков и одна внучка.

«Поэзию люблю с детства. В юности пробовала писать свои сочинения в основном о любви. А теперь пишу о Божьей любви, которая открылась мне через Спасителя Иисуса Христа во время тяжелой болезни, когда жизнь моя висела на волоске. Я бесконечно благодарна Всевышнему, который вел и ведет меня в этой жизни под своей защитой. Каждый новый день принимаю как подарок от Бога и благодарю Его в своих изложениях на родном языке», — говорит Найля Бариевна.

## РӘХМӘТ СИҢА

Рәхмәт Сиңа, яшәү бүләк иткән
Мәрхәмәтле, изге Аллага!
Мәхәббәтең һәм шәфкатең белән
Мине сөеп сайлап алганга.

Бурычлымын Синең алда, Аллам,
Аны мәңге кайтара алмам.
Тирән сөю һәм ышаныч белән
Инансамчы тик Сиңа, Аллам.

Яратырга телим һәркемне мин,
Мәхәббәтем әле җитми шул.
Кичерергә, яратырга өйрәт,
Тормышымда миңа терәк бул!

Сакла мине, Аллам, мин көчсезне,
Синнән башка гөнаһ колы мин.
Йөрәгемә кереп Үзең яшә,
Ышанычым минем бары Син,
Коткаручым минем бары Син!

## ГОМЕР ЮЛЫМ

Сүтә-сүтә хәтер йомгагымны,
Очын очка ялгап уйларымны,
Күзаллыймын гомер юлларымны
Һәм барлыймын үткән елларымны.

Гомер юлы бик тиз үтелсә дә,
Байтак икән абынган җирләр дә.

Күп бозылган куелган чикләр дә,
Күп кылынган бик яман эшләр дә.

Эх, аяныч, яман гадәтләргә
Җаным-тәнем шундый күнеккән!
Еллар буе җыйган гөнаһларым
Миңа инде тәмам береккән!

Үлем килсә бу гөнаһлар белән
Ничек барыйм Ходай каршына?
Бик соң булыр тәүбә итәргә дә
Кылган эшләремнең барсына.

Әле җаным тәнемдә чагында
Гөнаһларым өчен үкенеп,
Раббым, мине гафу итүеңне
Сорыймын мин Синнән үтенеп!

Кичер мине, Аллам, кичер мине,
Гөнаһ коллыгыннан Син коткар!
Иман биреп изге юлларыңнан
Мәңгелек тормышка алып бар!

## ДАН ҖЫРЛЫЙМЫН

И шәфкатле, изгелекле Аллам,
Исемеңне Синең зурлыймын!
Рәхмәт әйтеп Сиңа барысы өчен
Сиңа мәңгелек дан җырлыймын!

И сөекле, и кадерле Аллам,
Рәхмәт Сиңа барлыгың өчен!

Синең генә бар җиһанга җитә
Мәхәббәтең, шәфкатең, көчең.

Син — гүзәллек, Син — сөюнең үзе,
Күңелләргә шатлык бирүче!
Җаныбызга тынгы, йөрәкләргә
Сүнмәс бер нур булып керүче!

Синең белән миңа шундый рәхәт,
Һәрчак тоям мәхәббәтеңне.
Авыр чакта Син ярдәмче миңа,
Кызганмыйсың мәрхәмәтеңне.

Кыенлыклар, куркынычлар килсә,
Сыенам мин Синең куенга.
Һәм килгәндә шатлык-сөенечләр
Син буласың минем уемда.

И шәфкатле, изгелекле Аллам,
Яклаучым да, саклаучым да Син!
Бердәнберем, таянычым минем,
Син булмасаң ни эшләр идем мин?

## ГАИЛӘМНЕ САКЛА

Мин Ходайга рәхмәтлемен
Сине биргән өчен.
Сине миңа, мине сиңа
Тиң иткән өчен.

И Ходаем, үзең сакла
Гаиләмне минем!

Тормышымда бул җитәкчем,
Ярдәмчем минем.

Сакла безне явызлардан,
Яман эшләрдән.
Өйрәт Үзең тайпылмаска
Синең сүзләрдән.

Фатиханңны бирче, Аллам,
Калган гомеремә!
Мәхәббәт һәм иминлек бир
Минем гаиләмә!

## БАРЫСЫН ДА СИН БИРГӘНСЕҢ

Җир йөзендә бар табигать, хозурлыкны,
Тереклекне, гүзәллекне, матурлыкны —
Барысын да Син биргәнсең кеше өчен,
Сине данлап һәм шатланып яшәр өчен.

Рәхмәт әйтәм һәр сулышым, гомерем өчен,
Миңа, Аллам, биргән өчен яшәү көчен.
Изгелекне явызлыктан яклаучы Син,
Бар Галәмне яратучы, саклаучы Син!

## БАР ТАБИГАТЬ СИНЕ ДАНЛЫЙ

Һәрчак якты көнең туа,
Кояш сибә нурларын.
Гөлчәчәкләргә күмелә
Болыннарың, кырларың.

Син тудырган бу гүзәллек,
Бу рәхәтлек, хозурлык,
Ул җиләкле җәй айларың
Әллә нигә торырлык!

Матур Синең күзләрең дә,
Кышларың да күңелле!
Гөрләвекле яз айларың
Дәртләндерә күңелне.

Бар табигать Сине данлый,
И сөекле Ходаем!
Кошлар сайрый Сине мактап,
Мин дә кушылып җырлаем.

## КИЧЕР СИН МИНЕ

Кичер Син мине, и бөек Аллам,
Ничәмә еллар Сине белмәдем.
Мәгънәсез тормыш, гөнаһ эчендә
Үтте көннәрем, үзем сизмәдем.

Мин белмәгәнмен, тик Син икәнсең
Рухи үлемнән йолып алучы.
Мин гөнаһлыны шундый яратып,
Яшәү бирүче һәм коткаручы.

Рәхмәтле Аллам, шәфкатьле Аллам,
Сиңа багышлыйм мактау җырларын.
Мәрхәмәт кылып караңгылыктан
Якты юлыңа мине чыгардың.

## БЕЗНЕҢ АЛЛАБЫЗ ШӘФКАТЬЛЕ
### (ПӘЙГАМБӘР ДАВЫТНЫҢ МӘДХИЯСЕ)

Безнең Аллабыз шәфкатьле,
Гадел һәм ярлыкаучы.
Аның исемен чакырган
Тәкъвәләрне саклаучы.

Ул догамны ишеткәнгә,
Мин Аллама сыенам.
Ходай яхшылык кылганга,
Рәхмәт әйтеп сөенәм.

Тәмуг газапларын күрдем,
Чирдә, кайгыда идем.
Шулчак Ходайны чакырдым:
«Җанымны коткар!» — дидем.

Ул миңа колак салды,
Кысанлыктан чыгарды.
Кайгылардан тартып алды,
Һәм җанымны коткарды.

Җаным инде тынычланды,
Күзләремнән яшь акмый.
Аякларым да абынмый,
Чөнки Ходаем саклый.

Мин тереләрнең җирендә
Ходай белән булырмын.
Коткаручым Ул булганга,
Гел аңа сыенырмын!

## ИЗГЕ ХӘБӘР

Тыңлагыз, кешеләр, бу изге хәбәрне,
Тыңлагыз сез Алла турында.
Хәбәрләрнең үлемсезе булып,
Ул күчкән буыннан-буынга.

Күп гасырлар аша килеп җиткән,
Шушы хәбәр безнең көннәргә.
Бөек Аллам, Синең изге исемең
Кабатлана төрле телләрдә.

Мактау Сиңа, Раббым, һәм дан Сиңа,
Гәйсә булып Җиргә килгәнсең!
Безнең гөнаһларны Син Үзеңә алып,
Газапланып хаҗда үлгәнсең!

Үлгәнсең дә кабат терелгәнсең,
Коткарырга безнең җаннарны.
Алып барыр өчен мәңгелек тормышка,
Раббым, Сиңа инанганнарны.

Син — гаделлек, Син — мәңгелек яшәү!
Рәхмәт Сиңа, Бөек Аллабыз!
Синең үлемсезлегең алдында
Тезләнеп без сәҗдә кылабыз!



# КАЮМОВ
## ХАНИФ ГАФУРОВИЧ

Каюмов Ханиф Гафурович родился в 1947 году в деревне Богданово Балтачевского района Республики Башкортостан. После окончания в 1968 году Старобалтачевской средней школы поступил на экономический факультет Башкирского сельскохозяйственного института. После окончания института работал в колхозах и совхозах экономистом.

В 1996 году окончил Башкирскую Академию государственной службы и управления при Президенте Республики Башкортостан. Долгие годы работал председателем районной плановой комиссии, заместителем исполкома Балтачевского районного Совета народных депутатов.

После преобразования районных Советов в районные администрации работал заместителем главы администрации по экономике — начальником отдела экономики. С 2005 года, после выхода на заслуженный отдых, проживает в г. Агидель.

Рассказы и стихи печатаются в республиканской и местной печати. Победитель юмористического конкурса «Посмеемся вместе», который проводила республиканская газета «Омет». В 2018 году выпущена книга «Давыллы яңгыр».

## КОРЫЛЫК БӘЛАСЕ
## (ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ)

Ул елны бигрәкләр дә коры килде шул. Хәтта язгы карлар эреп беткәннән башлап, җир өстенә бер генә тамчы да яңгыр бөртеге төшкәне булмады бит. Инде елгалар корып бетте. Үләннәр дә, маллар да, инде кешеләрне әйтеп тә торасы юк, дымга, суга сусауның ар ягына чыктылар. Шундый эссегә чыдаулары да бик авыр инде, билгеле. Һаваның бөркүлеге хәтта мич авызыннан чыккан эсселек белән чагыштырырлык дәрәҗәгә җитте. Бу кадәрле озайлы корылыкка инде вак-төяк күлләр, елгалар да корып бетте. Алар гына нәрсә, авыллардагы коеларның да күбесе сусыз калды.

Әхмәтнурларның да бәләкәй генә авылларында булган өч коеның берсендә генә су калды. Ярый әле, бәхеткә, әлеге суы калган кое Әхмәтнурларныкы иде. Авыл халкының суга башка барыр җире беткәч, чарасызлыктан Әхмәтнур коесына йөри башладылар. Көн саен шулай дәвам итә торгач, бу хәл Әхмәтнурга һич кенә дә ошамый башлады.

Бераз уйланып утыра торгач, ахрысы башында акыллы бер фикер барлыкка килергә ашыга иде булса кирәк, башын кырын салып: «Тукта әле, хәзер бит илдә базар мөнәсәбәтләре хөкем сөрә. Дөнья эшкуарлар кулына күчеп бетеп бара. Нигә соң әле мин үземдәге коеның суын бөтен авыл халкына бушка таратып ятам? Нигә аның файдасын күрү турында әлегә кадәр бер дә уйламаганмын соң әле? Авылда сулы бердәнбер кое Әхмәтнурдамы? Әхмәтнурда. Димәк ул бүгенге көндә кем була инде? Дөрес! «Манапулис» була. Нишләп соң ул бүгенге көнгә кадәр бу турыда һич кенә дә уйлап карый белмәгән? Менә инде хәзер файдаланылмый калган күпме көннәр артта калды. Болай булмый,

иртәгәдән үк коедан алган суга «тариф» билгеләргә кирәк», — дип компьютер кебек башына шундый да акыллы фикер килүенә үзе дә ихлас шатланып куйды. «Шәп фикер бит бу», — дип уйлады ул. Ә хыяллар тагын үскәннән үсә барды.

Ул тиз генә өйгә, хатыны Фәһимә янына кереп, әлеге «гиниал» планын аның белән дә уртаклашырга ашыкты. Бу турыда ишеткәч тә, хатыны күтәрелеп бәрелде:

— Син ни сөйлисең? Үзебезнең авыл халкыннан коеңнан су алган өчен генә ни йөзең белән акча сорап утырырсың? — дип, ризалашырга якын да килмәде. Шунда Әхмәтнурның әле яңа гына барлыкка килгән «бизнис» планының комга төртелү куркынычын уйлап, аркалары чымырдап куйды. «Юк инде, алай гына булмый әле ул, — дип уйлады ул. — Һәр яңалык үзенә юл алганда гел каршылыкларга очрый тора инде ул. Көрәшергә кирәк, ышандырырга! Болай тиз генә бирешсәң, беркайчанда эшкуар була алмыйсың».

— Соң, әгәр безнең кое булмаган хәлдә, алар нинди уңайсызлыкларга дучар булырлар иде. Шулар турында аларга тырышып аңлатканда, сөенеп риза булачаклар бит,— диде ул Фәһимәгә. Үзенең «бизнис» планының отышлы якларын тагын әллә күпме сөйләде ул хәләленә. Матди яктан да күпме файда киләсен әйтми калмады, билгеле. Ахырда Фәһимә Әхмәтнур белән ризалашты. Матди якларын сөйләгәндә, болай да акчага битараф булмаган Фәһимә Әхмәтнурның бу адымына башкача каршы килеп маташмады. Хәзер мәсьәләнең иң мөһим баскычына килеп төртелделәр:

— Су өчен «тариф»ны күпме куябыз? — дип сорады Әхмәтнур.

— Синең «бизмәс» планың бит, үзең кара инде, — дип Фәһимә бөтенләй читкә үк китте.

— Алай булгач, литрына бер сумнан башлыйк әле. Әзрәк була инде булуын, ярар тора-бара күз күрер тагын,— диде Әхмәтнур.

Иртән суга килгән авылдашлары Әхмәтнурларның капкасында бозау башы кадәрле йозак күреп, аптыраштa калдылар. Озакламый Әхмәтнурның капкага таба килүе койма өстеннән генә күренеп калды. Капка ачылуга суга килүчеләр арасыннан Галимхан абзый:

— Нәрсә, энем, шул вакытка кадәр йоклап яттыңмы әллә? — дип, шаярткандай кеткелдәп алды. Тик Әхмәтнурның гына чыраенда бер үзгәреш тә күренмәде:

— Җәмәгать, менә үзегез дә күреп торасыз, заманалар үзгәрде бит хәзер. Бушка беркайда да берни бирмиләр. Район үзәгенә йомыш белән барып, берәр конторга барып керсәң, башлап ишеген ачкан өчен генә дә бит акча түләтәләр, ә аннан йомышыңны үтәгәнгә тагын түләргә кирәк, әгәр үтәлсә әле ул. Менә шуңа күрә мин дә эшкуарга әйләнергә булдым әле, кыскасы бүгеннән башлап минем коедан алган суның һәр литрына берәр сумнан түләргә туры килер,— дип туктап кына калган иде Әхмәтнур, суга килүчеләр арасында ризасызлык чыгып, тавыш-гауга китте. Ул тагын дәвам итте:

— Мин бит сезне һич ирексезләмим, әгәр инде минем шартлар белән килешмисез икән, пажалысты, дүрт ягыгыз кыйбла, башка җирдән эзлисез инде, — диде. Әхмәтнурның шаяртырга уенда да юклыгын инде барысы да аңлап алды булса кирәк. Галимхан абзый гына:

— Энем, бигрәк күп сорыйсың бит, ичмасам чабуыңны чак кына тарт инде. Болай бит кешене көпәкөндез талау була, — дип караса да, файдасы тимәде.

— Галимхан абзый, бердә алай түгел ул, әгәр мин кеше таласам, өегезгә кереп алып чыгып китәр идем. Ә болай сез үзегез алып килеп бирәсез дә, су алып

кайтып китәсез. Аермасын күрә белергә кирәк, абзый, — дип аның авызын тиз япты. Башка барыр җир булмагач, кеше кая гына барсын инде, алган суларына акча түләргә мәҗбүр булдылар.

Әхмәтнур җыелган акчаны кичтән санап, бик зур канәгатьләнү белән шкафка алып куйды. Чыгып, капканы бозау башлы йозакка бикләп кергәч, акчаны кая тотарга планнар корып озак кына утырды әле.

Икенче көнне суга килүче авылдашларның саны, башка көннәрдәге белән чагыштырганда, ике мәртәбәгә артып киткән иде инде. Бер уйласаң, хак куелгач, суга килүчеләр азаерга тиеш иде дә соң. Юк шул инде, алар хәзер базар кагыйдәләрен җитәрлек үзләштергәннәр иде. Билгеләнгән хак озак тормый, көн саен арта гына бара. Кешеләр дә «тариф» күтәрелгәнче күбрәк су алып калырга ашыктылар. Аларның борчылуы юкка булмаган икән шул. Клиентларның күпкә артуын күргәч, Әхмәтнур «тариф» ны шунда ук арттырып, суның литрына биш сумнан ала башламасынмы. Әлеге Галимхан абзый каршы торып азапланса да, үзенең яклылар табылмагач, шундук басылды.

Бу вакытта инде Әхмәтнурның кесәсенә акча елга булып ага иде. Ул керемнең көн азагына кадәр күпмегә җитәргә мөмкинлеген чамалап кына торганда, томан аша кебек Фәһимәнең ачулы тавышын ишеткәндәй булды:

— Әхмәтнур, җитәр инде сиңа, уян! Тагын күпме йоклап ятарга була? Тор тизрәк! Әнә шул эчеп йөрүең аркасында кичә суга да баралмадың бит,— дип хатыны әрләргә тотынды. Әхмәтнурның, әлеге булган хәлләрнең төшендә генә булуы кәефен нык кырды инде кыруын. Чынлап та авылдагы өч коеның икесе корыган иде шул. Бәхетсезлеккә каршы, шул ике коеның берсе Әхмәтнурларныкы. Бары тик түбән оч Галим-

хан абзыйларның гына коесында су бар. «Ярый әле суны Галимхан абзый Әхмәтнур төшендә күргәнчә, акчага сатмый», — дип куанды ул. Шулвакыт сыер савып кергән Фәһимәнең әле булса Әхмәтнурга булган ачуы басылмаган иде:

— Менә син артыңа кояш төшкәнче йоклап яткан арада Галимхан абзый суны акчага гына бирә башлаган икән. Әнә, шкафтан акча ал да, тизрәк йөгер суга, бүген дә сусыз калмыйк! — дип ашыктырды. Бу сүзләрне ишеткәч, Әхмәтнур лып итеп артына утырды. Шулай да, тиз генә киенеп алды да, акчасын кесәсенә салып, бәлкәй арбасына битунын утыртты да, суга чыгып йөгерде. Ул барып җиткәндә суга килүче кешеләр азайган иде инде. Әхмәтнурның чираты җитеп коега якынлашуга, Галимхан абзый:

— Әхмәтнур, ишеткәнсеңдер инде, мин бит хәзер эшкуар булып киттем, суны бүгеннән башлап акчага гына бирәм. Суның литры ун тиен тора, — дип, аны «тариф» белән дә таныштырып алды. Әхмәтнурның бу хәлгә исе китеп:

— Галимхан абзый, син нишләп шулай көпә-көндез авылдашларыңны талыйсың? — дип, аны оялтырга тырышып караса да, тегесе үз сүзендә нык торды:

— Кем, Әхмәтнур энем, без бит инде күптән базар мөнәсәбәтләрендә яшибез. Синдә — акча, миндә — тауар. Әгәр син шуңа риза түгелсең икән, бигайбә, суны башка җирдән эзлисең инде, — дип борылып кереп үк китә башлады. Кызганычка каршы, Әхмәтнурга башкача бер генә юл да юк иде шул, чөнки авылда башка су чыганагы юк. Битуны тулганчы су алып, тиешле акчасын түләүдән башка чара калмады аңа. Тәгәрмәчләре майланмаган арбасына су тутырылган битунын утыртып алды да, әкрен генә аларның күңелсез шыгырдавын тыңлый-тыңлый өенә таба юнәлде.

## БӘРӘҢГЕ БАКЧАСЫНДА

### (ЮМОРЕСКА)

Кояш рәхимсез кыздыра. Яздан башлап бер тамчы да яңгыр бөртеге төшкәне булмады бит, ичмасам. Җәйнең шулкадәр эссе килүенә һушларың китәрлек булды инде. Билләһи, дип әйтәм, җәйнең бу эссе мәлләрендә кышның салкын көннәрен сагынып искә алмаган кеше сирәк булгандыр. Шулай булмый ни, кыш көне бит салкынлыгына карап киенсәң, җылынып та була. Ә бит мондый эссе көндә бөтенләй чишенеп ташласаң да, аннан качып котылып булмый.

Әлеге эссе көннәрдә Себердә вахта ысулы белән эшләп йөргән Фәрит ялга кайтып төште. Ара бик ерак булганлыктан, билгеле, бик еш кайта алмый иде ул. Бу юлы аның кайтуын хатыны Сәкинә дә, тыны белән суырып алырдай булып, зарыгып көтте. Сагынудандырмы, юктырмы, анысын белмим, тик бәрәңге күмәр вакытлары җитеп беткән иде. Ахрысы, Сәкинәнең Фәритне көтүе дә шуңа бәйле булды бугай. Аны утыртканда да Фәрит читтә эштә булуы аркасында туры килмәгәч, күмәргә аңа туры килә иде инде. Район үзәгендә яшәгәч, ихатада җир участогы нибары яшелчә-җимеш үстерерлек кенә. Шунлыктан, бәрәңгене авыл читендәге басуда бүленеп бирелгән участокта утырталар иде.

Авылдан ераграк булса да йөриләр инде, нишлисең, бәрәңге утыртырга кирәк бит. Сәкинә балалар бакчасында эшләгәч, аннан берничек тә эшен калдырып бәрәңге күмәргә йөри алмады. Фәритне хатыны икенче көнне таңнан ук уятып бәрәңге җирен эшкәртергә җибәрде. Нихәл итәсең инде, барырга туры килә. Сезонлы эш бит, эссе дип бармый калып булмый, чөнки талгын көннәр булыр әле дип, бу эшләрне көзгелеккә калдырып булмый бит инде.

Фәрит абзарда торган «матай» ны ишек алдына алып чыгып кабызды да, аның бишегенә кәтмәннәрен салып, басуга бәрәңге җирен эшкәртергә китте. Анда барып җитеп, бәрәңге җиренә күз салса, артына чак кына авып китмәде. Андагы чүп үләннәре сирәк-мирәк кенә күренгән бәрәңге сабакларыннан да байтак биек булып үсеп киткәннәр иде. Гөнаһ шомлыгына мәйданы да зур гына бит әле — егерме сутый тирәсе иде булса кирәк.

Фәрит шунда ук трусиктан гына калганчы чишенеп ташлады да, эшкә дә тотынды. Тик кояшның рәхимсез кыздыруы өстенә, чүп үләне белән бергә болай да зәгыйфь кенә үскән бәрәңге сабаклары да йолкынып чыгып, барлы-юклы кәефне кыра иде инде мәгәр. Җәйнең шундый эссе озын көннәрендә, кызу кояш нурлары астында бу эшне башкару ай-һай җиңел эш түгел икән шул. Фәрит күңеленнән генә бу эшне башкарасы урынга себердә хәтта чираттан тыш вахтада эшләргә дә бик теләп риза булыры турында бик еш уйланды. Бик эсселәгән чакларда әзрәк кенә булса да ышыкланып хәл алырдай күләгәсе генә дә юк бит аның. Берничә көн тырыш хезмәт салганнан соң инде җир башында чүп үләннәреннән зур гына чүмәлә өелгән иде инде. Кояш нурлары үзенекен итте, Фәритнең себердә йөреп кайчаннан бирле инде болай ук кыздырган кояш астында түгел, юньләп җылыткан кояшны да бик сирәк кенә күргән тәне дә ачыграк тәнле негрларныкына ошап калды.

Ничек булса да тырышты Фәрит, бер атна чамасы вакыт үтүгә бу эшне тәки ерып чыкты. Иртәгәсе көнгә эше дә әз генә калды, Сәкинәнең дә ялы булгач, аның белән килербез дип, күңеле булып кайтып китте ул бу көнне.

Кич белән ашап утырганда, Фәрит бик зур хәрби замокны штурмлап дошманнан азат иткән кеше кебек тойды үзен. Сәкинәгә:

— Әйдә, иртәгә син дә минем белән барып килерсең басуга, эш әз калды инде анда. Шунда бер ыңгайдан минем атна буе башкарган эшемне дә кабул итеп алырсың, — дип аны да күндерде. Иртән басуга барып, Фәрит тимер атын урнаштыруга Сәкинә кычкырып җибәрде:

— Атна буе эшләгән эшең кая соң синең, хәчтрүш? Бакчага кеше кулы да кермәгән бит монда, — дип, Фәритне бик урынлы итеп кыздыра башлады. Фәрит Сәкинәнең кеше бакчасына карап, аны эссе табада кыздыруына елмая биреп:

— Менә бит минем эш монда, бирегәрәк килеп кара, нәрсә дип кеше бакчасы турысына туктап мине әрлисең әле? — дип үзенең дә ризасызлыгын белдерә башлаган иде, Сәкинә аның саен ярсып:

— Ахмак! Син Сәлимнәрнең бакчасын эшкәрткәнсең бит.

Бу сүзләрне ишетүгә болай да үтә яман кыздырган кояш нурлары Фәриткә җәядән аткан уклар булып кадалгандай тоелды, башы әйләнеп китеп, егылып китә язды хәтта. Чынлап та, аларның бәрәңге участогы бит йорт күршеләре Сәлимнәрнең участогы белән басуда да янәшә туры килгән иде бит әле. Менә сиңа, әллә җирне бик сирәк күргәнгә, әллә чүп үләннәренең котырып үсүе аркасында, Фәрит үзләренең участогын Сәлимнәрнеке белән бутаган булып чыкты. Еласаң да күңел тынычланырлык түгел, бер атна буена күршесенең бәрәңге җирен эшкәрткән булып чыкты бит.

Хатыны белән башкача берни дә сөйләшеп тә тормыйча, матайга утырып, тырылдатып кайтып та киттеләр. Фәритнең кәефе бакчаларына көтү маллары кереп, бөтен үстергән яшелчәләрен таптап чыгып киткән кебек, бик төшенке иде.

Ул күршеләре Сәлимнәргә кереп, килеп чыккан хәл турында аларга да бәян итте. Ә алары, куанасы урынга, киресенчә ачулана башладылар.

— Бәрәңге рәтле-башлы чыкмагач, без аны утап та тормаска булган идек. Чүп үләннәре белән бергә чабып алып печән ясарга чамалаган идек. Печән хәзерләргә быел бит үлән корып бетте. Ничек безнең рөхсәтсез кереп бакчаны утадың? — дип пыр туздылар. Фәрит ык-мык итте дә, тизрәк чыгып китү ягын карады.

Фәритнең ялгыш кешенең бәрәңге участогын утап, үзләренеке шул килеш калуы гына җитмәгән, тегеләренекен утаганы өчен дә бәлагә кала бит хәзер. Ул шулай да кичкә таба кибеткә барып бер ярты алды да, күршеләренә кереп китте. Әлеге зәм-зәм суы шешәсен бушатып утырган арада Сәлим бераз йомшара төште, хәтта иртәгә Фәритнең бәрәңгесен уташырга барырга да риза булуын әйтеп куйды.

Фәрит белән Сәлим икенче көнне үк Фәритләрнең бәрәңге бакчасын утый да башладылар, тик эшкә генә икесенең дә күңелләре бик төшеп бармады. Фәриткә икенче бакча эшкәртергә туры килгәнгә инде, ә Сәлимгә ни билгеле инде, үзенеке уталган бит, кешегә кемнең генә эшлисе килсен инде ул, үз бакчасы түгел бит, димәк «стимулы» да юк. Күрәсең, шуңа күрәдер инде, Фәрит башта үз бакчалары дип, Сәлимнәрнекен эшләгәндә берүзе генә дә атна эчендә башкарып чыккан иде. Бу юлы икәү эшләсәләр дә, ул тагын атна буена сузылды. Эшләрен башлаганда күңелләре бик төшенке булса да, эшләре тәмамлангач, алайда кәефләре күтәрелеп киткәндәй булды, чөнки ике бакча да эшкәртелеп бетте бит.

Ә Фәриткә иртәгә эшкә китәр вакыты да җиткән иде инде. Эшкә барып, эшли башлагач та әле, баштарак төннәрендә еш кына Фәритнең төшенә уталмаган бәрәңге җирләре кереп, бимазалап бетерде.



# МИНАХМЕТОВА
## ЗАЛИФА ХАНАФОВНА

Минахметова Залифа Ханафовна родилась 18 августа 1963 года в деревне Саузово Краснокамского района. В 1980 году поступила в БГПТУ №10 и выучилась на крановщицу. В городе Агидель проживает с 2000 года. В настоящее время работает кондуктором в городе Нефтекамске. В свободное время много читает и пишет стихи. Ее стихи часто публикуются в местной газете «Аҡ калам» и в газете «Кама таңнары».

Залифа Ханафовна участвовала в региональном конкурсе художественной самодеятельности «Башавтотранс — моя судьба!», посвященном 90-летию со дня основания предприятия. Первый этап этого конкурса проходил в городе Бирске, где Залифа Ханафовна заняла III место в номинации «Разговорный жанр». На втором этапе, который проходил в г. Уфе, Залифа Ханафовна удостоилась приза зрительских симпатий и получила подарок от известного поэта-песенника Рамиля Чурагулова с личным автографом. Дипломант Межрегионального литературно-поэтического фестиваля-конкурса устного творчества «Ата-бабалар ауазы» — «Зов предков».

## УЙЛАР

Белсәң:
Ниләр уйлап йөргәнемне,
Кан сауганын йөрәгемне.
Уйларымнан арыналмый,
Сагышлардан саргайганны,
Үрсәләнеп елаганны,
Яшь аралаш елмайганны,
Кайгыларга чыдаганны.
Яшь кибәрме?
Чыдамлыгым озаккамы?
Сабырлыгым — сары алтын,
Сынауларга түзәлерме?
Алдымдагы киртәләрне
Күңел күгем күтәрерме?
Күңел күзем дус-дошманны
Керфек аша үткәрерме?

## ЯЗМЫШ СЫНАУЛАРЫМ

Тормыш юлымдагы чакрымнарым
Сикәлтәле булды, бормалы.
Бирешмәдем, авырлыкка түздем,
Тәкъдирем, дип, язмыш сынавым.

Язмыш дилбегәсе үз кулымда,
Кай тарафка борсам хәерле?
Уңга, сулга, бәлки, туп-турыга,
Тик булмасын гына хәвефле.

Яшәештә кылган ялгышларым
Яман төштәй артта калырмы?

Авыр чакта фәрештәмнең уңы
Иңнәремә кулын салырмы?

Язмыш сынауларым, ишетегез,
Мин бит көчле адәм баласы.
Шатлыклары, кайгылары белән
Тәгәридер тормыш кысасы.

Туганнарым, дус — ишләрем белән
Язмышымда килә каласы.
Мин — бәхетле бәндә баласы!

## КАЙТАВАЗ

Соңгы яфрак төште агачыннан,
Агачыннан төште өзелеп.
Күзге күктә, күктә каңгылдап,
Кыр казлары очты тезелеп.
Бәгеремне телеп, балачакны,
Балачакны искә төшереп,
Саубуллашып кыр казлары
Каңгылдашып китә тезелеп,
Үзәккәем кала өзелеп.
Ялгыз калам — калам көенеп,
Артларыннан карап — кызыгып.
Җаным өши, мамык шәлгә,
Мамык шәлгә торам төренеп.
Күңел белән очам яннарыңнан,
Канатланып калам, ашкынып.
Кыйгак-кыйгак ките кошкайлар,
Кайтавазда калды уралып.
Мамык шәлгә, мамык шәлгә
торам төренеп.

## ЫШАНАМ

Туасы таңнарга, явасы карларга,
Горур ай янында балкыган,
Йолдызлар явына сокланган,
Шәфәкъкә батасы,
Офыктан калкасы кояшка,
Тыныч төннәргә,
Якты көннәргә сөенәм.
Киләсе язларга,
Буласы назларга,
Туасы җаннарга ышанам.
Болытсыз күкләргә,
Тибәсе йөрәккә,
Шатлыктан агасы
Яшьләрем барына ышанам.
Дөньяда яшибез —
Мин шуңа куанам!

## ЙӨГЕРӘМ

Ялантәпи йөгерәм абыйларым артыннан,
Чыклы бәбкә үләннән йөгерәм юри.
Яланаяк йөгерәм балачагым артыннан
Яшел чыклы чирәмнән.
Челтер чишмәләргә юл табып,
Челтер чишмәләргә серем сөйләп,
Салкын суларында юындым.
Озак еллар саклап килгән
Хатирәләр белән юандым.
Кояш нурларына иркәләнеп,
Яшәү бәхетен куандым.
Төшләремдә йөгерәм абыйлар артыннан,

Хыялымда йөгерәм балачагым артыннан.
Йөгерәм, ялантәпи йөгерәм,
Чыклы бәбкә үләннән
Йөгерәм, йөгерәм.

## САТАШТЫМ

Төшемдә саташтым,
Назландым, сөелдем,
Бер мизгел гөнаһка бирелдем.
Онтылдым.
Өнемдә — чынбарлык,
Абындым, упкынга убылдым.
Нишләдем?
Тәгәри яшьләрем, алдандым:
Минутлык хисләргә бирелеп,
Үземне кимсеттем.
Ник син, төш, өнемә ялгандың?
Түбәнчелек белән башым иеп
Үз-үземнән гафу үтенәм.
Соң булса да һаман үкенәм,
Тик шулай да китмә, үтенәм!
Түгел кешегә бәйләндем,
Тәңрем, мин кемгә бәйләндем?

## КАР БӨРТЕГЕ

Кар бөртеге учларымда эри,
Карашыңнан килә эрисем.
Өндә күрүләрдән мәхрүм,
Төшләремә керче — кочасым,
Мизгел генә килә күрәсем,
Чәчләреңнән сыйпап үтәсем.

Кар бөртеге учларымда эри,
Назларыңнан килә эрисем.
Айлы төндә йолдызларны санап,
Таң атканын килә күрәсем.

Кышкы көннәр кыска, төннәр озын,
Һич тә килми ялгыз каласым.
Салкын төндә сулышыңнан эреп,
Кочагыңда килә каласым.
Кар бөртеге учларымда эри.

## БАЛАЛАРЫМ

Бар мөлкәтем — бавыр каным —
Балаларым, бәгырьләрем.
Кызым — кояш,
Улым — ай,
Үзем — әче әрем.

Бар байлыгым —
Киң күңелем, олы йөрәк.
Кызым — тырыш,
Улым — терәк,
Миңа кирәк.

Бар өметем — балаларым,
Кызым — җимеш,
Улым — көмеш,
Алар — минем өлеш.
Атлый киләм
Шәл чугымны җилгә бәреп,
Кызым — көмәч,
Улым — көләч,
Үзем — бәхетле әни!



# САЛИХЯНОВА
## РАФИСА МАГАНАВИЕВНА

Салихянова Рафиса Маганавиевна родилась 8 сентября 1958 года в деревне Старый Аткуль Краснокамского района. После окончания школы около пяти лет работала на швейной фабрике в г. Иваново. Вернувшись в г. Нефтекамск, получила образование бухгалтера и начала работать в управлении НГДУ «Южарланнефть». Вышла замуж, вскоре молодая семья переехала в г. Агидель.

Тяжело заболев, Рафиса ушла с работы, в то же время заочно училась в Агидельском филиале УТЭК.

Ее первый рассказ «Жизнь как подснежник» — о трех братьях своего отца, совсем молодыми погибших на фронтах войны, — публикуется в газете Краснокамского района и удостаивается диплома победителя конкурса, посвященного 60-летию победы в Великой Отечественной войне. Рафиса Маганавиевна начинает сотрудничество с газетой «Камские зори». Затем становится корреспондентом газеты «Ак калам». За два года работы она успевает завоевать любовь читателя. В конкурсе «Лучшие женщины Агидели», посвященном 35-летию города, ее награждают в номинации «Женщина-Творчество». В последние годы рассказы Р. Салихяновой публикуются в газете «Кызыл тан», журнале «Тулпар». Автор награждена Благодарственным письмом редакции газеты «Кызыл тан». Ее проза и стихи вошли в сборник агидельских литераторов «Между прошлым и будущим». В настоящее время Рафиса Салихянова возглавляет литературное объединение «Агидельские родники» при Центральной городской библиотеке.

## ӘТИЕГЕЗГӘ РӘНҖЕМӘГЕЗ

Язның беренче кояшлары күренү белән туган шәһәренә юл алды Миләүшә. Ваемсыз чагыннан язмышы белән сыналса да, бүген тормышы бөтен аның ике сабые, ышанычлы тормыш иптәше, яраткан эше бар. Фатирларын да үзләре эшләп алдылар. Аны заманча итеп җиһазландырып, төзекләндереп күчтеләр. Кирәк вакытта таяныч булырга, оныкларын өзелеп яратучы, ерак түгел авылда кайнанасы белән кайнатасы яши.

Мизгел генә булып хәтерендә сакланган бәхетле балачагы, газиз әнисе истәлеге аны туган фатирында көтәдер кебек, бүген дә ашкына күңеле. Әмма ишек алдына үтеп, буяулары кубып беткән фатир тәрәзәләрен эзләп табу белән, Миләүшә чынбарлыкка кайта, үсмер балалар күтәрә алмаслык хәсрәт, мәңгелек кайгы яшәгән бу тәрәзәләр аны кабаттан бала чагына алып кайта.

Тулы гаиләдә мәхәббәт җимеше булып туган кыз кечкенә чакларын бик матур картина итеп күз алдына китерә алыр иде бүген. Кояш кебек балкытып гел дә якты төсләргә генә бизәр иде ул аны. Нурлы кояш булып мәңгелек хәтерендә сакланган әнисе, төскә-биткә бик тә чибәр, зифа буйлы, уңганлыгы, җитезлеге белән «җитез Нәзирә» кушаматы алырга өлгергән мөлаем хатын булды ул.

Бик юмарт та булгандыр күрәсең, күршеләре аларга еш кына йомышка кererләр иде. Тик нигәдер биреп чыгарган әйберне кире керткәнне генә бер дә яратмады әниләре. «Кертмә дигән идем бит», — дип һәрвакыт канәгатьсезлек белдереп кала. Кайберсенә күтәреп кергән әйберләрен кире биреп чыгарган вакытларын да хәтерли Миләүшә.

Ике сабыена, күрше кызларына матур күлмәкләрне дә гел ул тегеп кидерде. Кызларының ничек укуларын күзәтеп торды, кызлар икесе дә сәнгать мәктәбенең рәсем бүлеген тәмамладылар.

Матур яшиләр иде алар. Фатирларында чисталык, пөхтәлек, утырып чыгып китәргә «Москвич» машиналары да бар. Бәләкәй чагында әтиләренең эчеп та тавыш чыгарганын хәтерләми Миләүшә. Сөеп-яратып, назлап, ни теләсәләр, шуны алып бирер иде кызларына.

Кешеләр көнләшерлек итеп яшәп ятканда, кызлары үсеп читтә укырга урнашкач, кинәт кенә әтиләре эчә башлады. Берничек тә җаен таба алмаган әниләре, чарасызланып, улы белән сөйләшергә дип бианасын да чакырып карады. Башын юләрлеккә салган ир, киресенчә, усаллашып, кунарга да кайтмый башлады. Йорт мәшәкатьләрендә генә кайнап, булганына куанып яши белгән әниләре, берара югалып калгандай булды. Хәсрәтен читкә чыгарырга кыенсындымы, серләрен кызлары белән бүлеште.

Каникулларының соңгы көннәре. Кадерен белеп калыйм дигәндәй, Миләүшә ул көнне бик озак йоклады. Әнисенең дә ял көне булгандыр күрәсең, кичә кичтән әтисенә юлга дип пешерелгәннән калган пирожкиларын җылытып куйган, чәй эчәргә утырдылар. Әтиеңнең командировкасы ешайды дип зарланып та алды әнисе.

Шулвакыт ишек шакыдылар. Кулына ниндидер кәгазьләр тоткан хат ташучы килеп керде. Ишек төбендә нидер сөйләнеп алдылар да, аны да чәй эчәргә чакырды әнисе. Йөреп ачыккан булдымы ул хатын, бер чакыру белән килеп тә утырды. Чәен бер йотып, кулына пирожки алып бер кабу белән:

— Карале, мин мондый пирожкины берәүләрдә ашаган идем инде бүген, синең ирең кайда? — диде, ачыш ачкандай сораулы карашын әнисенә юнәлтеп.

— Командировкага китте бүген иртән, — диде әнисе ашыгып.

— Өстендә шакмаклы күлмәк идеме?

— Әйе, нигә? — соравына сорау белән җавап кайтарды әнисе.

— Нигә дип, мин пирожки ашаган хатынның йокы бүлмәсендә дә шакмаклы күлмәк кигән ир йоклап ята иде, аның ире юк бит, аптырап соравым инде, — диде ул берни булмагандай һәм чәен дә эчеп бетерми ашыккан булып чыгып та китте.

Шикләнергә урын калдырмады хат ташучы. Өйдә тавыш тагын да ешайды. Әтиләре әниләренә кул күтәрә башлады. Зур гәүдәле, исерек әтиләрен әниләренә сукканда аерып алу мөмкин түгел иде. Күрше абыйларына йөгереп кереп, берничә кабат ярдәм сораган чаклары да булды кызларның. Әтиләре балаларының үгет-нәсихәтен, ә әниләре участковыйга әйтик дигәнне ишетергә дә теләмәде.

Әниегез дәваханәдә, дигән хәбәргә укуларын ташлап кайтты кызлар. Әниләренең хәле шулкадәр авыр иде, ни булды дигән сораугa җавап та бирә алмады. Ушсыз өч көн, өч төн яткач, бар көчен җыеп «Әтиегезгә рәнҗемәгез!» диде дә, якты дөнья белән хушлашты.

Эче авыртуга чыдый алмый, ашыгыч ярдәм машинасын үзе чакырткан ул. Табиб биргән сөземтә кызлар күңеленә тагы да ныграк шик өстәде. Хәлнең ничек килеп чыгуын чамаласалар да, елый-елый сабыр иттеләр, беркемгә берни сөйләнмәделәр, әниләрен югалту ачы кайгы булса да, «үтерүче» кызлары буласы килмәде аларның.

Әниләрен җирләгәндә тынсыз гына йөргән әтиләре, «кызларым» дип өзелеп тормады, аралашулары гел үртәш-талаштан торды. Тора-бара әтиләре өчен кызлар дошманга әйләнде. Гөрләп торган гаилә юкка чыкты. Әтиле көе кызлар шыр ятим калды.

Күршеләреннән кыенсындымы, фатирына хатын алып кайтмады әтиләре. Үзе йортка барып керде дә, күчеп китте. Хатыны тиз генә ир бала табып бирде. Аның тормышы гөрли иде. Җиде юл чатында калган кызлар, читтән торып укуга күчеп, укуларын тәмамлады. Чит шәһәрдә эш табып урнаштылар, түләү мөмкинлеге булмагач, фатирларына бер ханымны вакытлыча яшәргә кертеп, тынычланганнар иде. «Баеп ятмасыннар әле» дип, әтиләре ул ханымны куып чыгарган.

Сата алмасыннар дигәндер инде, кызларга әйтми генә икенче хатыныннан туган улын да пропискага кертеп куйган.

Түләнмәгән квартплата бурычы, берничә ел үткәч, әтиләре белән суд залында очраштырды кызларны. Урамда күрсәләр танырлар иде микән алар әтиләрен?! Мәһабәт гәүдәле, куе кара чәчле, типсә тимер өзәрлек әтиләре, ак чәчле, бөкерәеп таякка таянган бабайга әйләнгән — алыштырып куйганнар диярсең! Янында бөтерелгән яшь хатыны кызына тиң! Күргәч тә кызганып йөрәге кысылды Миләүшәнең. Чирнең дә катысы эләккән икән бит: ике кабат инсульт кичергән.

— Үткәнең тыңгылык бирмәдеме, әти? Азгын хисләреңә бирелеп, бәхет ояңны җимергәнеңне хәзер аңлагансыңдыр, бәлки! Безне вакытсыз ятим итеп, әнисез калдырдың, мәнсезлегең аркасында хәзер муеннан бурычка батырдың. Әни, менә хәзер әтинең рәнҗер урыны да калмаган! — диясе килде күңеле тулган Миләүшәнең.

## БАЛА ГАЕПЛЕМЕ?

Язмышлар кабатлана… Ә нигә? Гөлүсәнең ялгызлыктан чара таба алмый мендәр кочып үксеп чыккан төннәре, балам ятимлекне, җитмәүчелекне тоеп үсмәсен дип икешәр эштә эшләп өзгәләнүләре — болар барысы да юкка булдымы? Кайда ялгышты ул? Бәлки, аның язмышы гел сынаудан гына юралгандыр? Язмышына башын иеп, сабыр гына яшәп яткан Гөлүсәнең җанын оныгы белән булган хәл тетрәндерде, онытырга тырышкан узганын айкатты.

Чәчәкле болыннар белән серләшеп, чиксез елгаларда су коенып, ялан-әрәмәләреннән үз куллары белән җиләк-җимеш өзеп ашап үскәнгәме, авылыннан бер дә чыгып китәсе килмәде кызның. Ә кирәк иде, ниндидер һөнәр алырга, укып, олы тормыш юлына аяк басарга иде аңа. Әгәр дә авылларында сыер фермасы булса, һичшиксез, сыер саварга гына барыр иде дә, булмады шул. Ярты җанын туган авылында калдырып, кыз башкалага чыгып китте. Төзүчеләр әзерли торган училищега укырга барып керде. Беренче карашка йомшак кына күренгән сипкелле кыз укуга бик тырыш булып чыкты. Төннәр буена ятласа ятлады, укуын гел яхшы билгеләргә генә тәмамлады. Тырыш яшьләр үзебезгә дә кирәк дипме, укуы беткәч, аны башкалада калдырдылар. Тулай торакка урнашып, яхшы гына эш башлап җибәрде кыз. Беренче мәлдә авылы турындагы уйлары белән йокларга ятып, төшләрендә авылы белән саташса, тора-бара авылын иң кадерле, иң газиз бер хатирә итеп йөрәк түренә бикләде дә, шәһәр тормышының хатын-кыз өчен күпкә җиңеллеген тоеп, ничек тә шәһәрдә төпләнергә ниятләде.

Сайланырга мөмкинлеге күп булса да, яңа тормыш башлап җибәрергә шәһәр егетен сайлады. Озак аралашмый гына алар өйләнеште. Бала туганчы бар да яхшы барды кебек. Бала тугач ни өчендер улларының тынычсызланып елавын да яратмады яшь әти. Бала карашуны уйлый да белмәде. Хатыны ярдәм итүен сораса, тавыш чыгарып, азаккы сүзен гел «авыл карачкысы», «җир корты» дип, үзе уйлап тапкан кушаматлар белән мыскыллап, өйдән үк чыгып кача да, төнгә эчеп кайтып, төннәр буе котырып чыгар иде. Бар бәхетсез хатыннарныкына охшаш иде Гөлүсәнең көнкүреше. Эндәшмәде, ир балага әти кирәк, яши–яши тынычланыр дип юандымы, ничек бар, шулай яшәп яттылар.

Балага яшь ярым булгач, эшкә чыкты. Улын балалар бакчасына урнаштырдылар. Үтергәнче сукмый әле, үз баласы бит, тәрбияләве шулайдыр инде, нишлисең, эндәшсәң, кара тавыш чыга дип, иренең кыланышларын күрмәмешкә салышса да, эченнән яна иде ана кеше. Вакыты-вакыты белән аның бу фатирдан чыгып качасы, улын үзе йөгереп үскән яланнарда йөгертәсе, үзе сулаган саф һаваларны сулатасы килде. Ләкин, юк, ирдән аерылып авылга кайту мөмкин түгел, хурлык бит.

Кая булса да читкә, Себер якларынамы, Казахстан далаларынамы? Шундый уйлар белән яшәп ятканда, үзебездә зур төзелеш ачылганын ишетеп, кызыксына башлады Гөлүсә. Бер көнне чираттагы йокысыз төннән соң, баласының киемнәрен генә җыеп алды да, автовокзалга юл тотты ул. Илдә чыпчык та үлми дип, үз-үзен юатса да, аларны колач җәеп каршы алучы булмады. Улын калдырырга урын юк, төзелештә балалар бакчасы җитешми. Балалар бакчасына аз гына

акчага җыештыручы булып урнашкач, балага урын табылды табылуын. Улы укый башлау белән төзелешкә эшкә күчкәч, фатирны да тиз алдылар. Муллыкта яшәмәсә дә, җаны тыныч иде ана кешенең. Юньсезлекне күреп үсми, тәүфыйклы булыр балам дип эченнән куанды. Үзе йортындагы тынычлыкны югалтудан куркып, сораучылар булса да, тормышка чыкмады.

Бала бәхете өчен яшәргә күнеккән ана, улы яшь булса да, өйләнәм дип кайткач, каршы килмәде. Булачак киленен дә бер күрү дә ошатты. Туйлардан соң матур итеп яшәп киттеләр. Өчесенең дә эше бар. Иртән торалар да эшкә китәләр, кичен көлешә-көлешә кайтып җыелалар. Бәхет өчен күп кирәкми бит, килененең авырлы икәнен белгәч, куануының чиге булмады Гөлүсәнең. Килененә ни тели шуны табып ашатырга тырышты, йорт эшләрен үзе башкарды. Ялгышамдыр дип үз-үзен юатса да, никтер улының гына йөзендә шатлык чаткылары күрмәде ана. Бала тугач, улын үзгәртеп куйдылармыни: бернинди сәбәпсез өйдә тавыш чыгара, аңа сабыйның елавы да ошамый, сез икәү бит дип, бала карарга да булышмый. Улының кыланышыннан куркып калды ана. Нәкъ әтисе! Әтисе белән аралашып яшәсә бер хәл. Күрәсе килеп сорашканы булмагач, Гөлүсәнең аның турында сүз кузгатканы да булмады. Синең әтиең вәхши дип әйтүдән курка иде. Ана кеше узар, яши-яши күнегер дип, күбесен күрмәмешкә салышса да, килене канәгатьсезлек белдереп, ата булган кешенең үз баласына игътибарын даулады. Авыр, бик авыр иде Гөлүсәгә килененддә үз язмышы чагылышын күрү. Улы да карап торган бер өмете. Өзгәләнә-өзгәләнә, бәлки, минсез берәр җае чыгар дип, килене белән киңәшләште дә, авылга, ялгыз әнисе янына юл алды Гөлүсә.

Алты ел алты көн кебек үтеп китте. Бәхет эзләп чыгып киткән бик күпләрне кабул иткән кебек, туган авылы халкы аны да үз итеп кабул итте. Ә инде кендек каны тамган туган туфрагының җылысы, гөлчәчкәле ялан-болыннары, чылтырап аккан чишмә сулары язмышыннан талчыккан күңел бушлыгын тутырырга ашыктылар кебек. Җәйләрен кунакка кайткан оныгы аларның тормыш-көнкүрешен тагын да бизәде. Авылны яраткан кызының туган нигезендә ныклап төпләнүенә куанган әнисе генә шушы вакыт арасында кызына мәңгелеккә бәхиллеген биреп, бакыйлыкка күчте.

«Әни, кайт, мин кияүгә чыгам» диде дә, тиз генә элемтәне өзде килене. Заманына күрә көн күргән хәзерге яшьләрдән ни көтәсеңне белмәсәң дә, берни аңламый, аптыраган хәлдә юлга чыкты Гөлүсә. Кайтып керсә, хәл аптыраудан узган иде. Улы белән килене закон аша аерылганнар, килене беренче мәхәббәте белән никахлашырга да өлгергән. «Ә бала?» — дигән сорауга килене: «Әни, үзеңне бел, сездән аермалы буларак, мин баланы әтисеннән аермыйм, сезнең кебек балага табынып яшәргә дә җыенмыйм!» — дип җавап бирде коры гына. Сораулар, тиргәшүләрнең мәгънәсе калмады. Гөлүсә улы янына күченеп кайтты. Акылы белән йөрәге көрәште ананың. Үзенчә киленен аңларга тырышса да, гафу итә алмады ул аны. Газиз улы белән дә уртак тел таба алмады. Бар куанычы һәр көнне читтән булса да онысын күрү иде. Урамда очрашсалар, онысы йөгереп килеп кочып ала, ләкин ике йорт аша гына яшәсәләр дә, фатирга керми, чакырсаң, башын аска иеп тора да, китәргә ашыга. Үз улының бала өчен өзгәләнеп тормаганын белгәнгә монсына да күз йомды ана. Онысының мәктәпкә

барганын-кайтканын күзәтеп тора. Балаларны хәзер мәктәпләргә үзләрен генә йөртмиләр, эшеннән ничек китәдер, оныгын килене үзе йөртә. Атнасына өч көн сәнгать мәктәбенә оныгы үзе генә йөри. Моңа эче пошкан Гөлүсә оныгына сиздерми генә артыннан озатып бара да, каршы алып фатирына кадәр озатып куя торган булды. Яңгырлы көзләрне, салкын кышларны уздырып, кояшлы язга чыккач, бер көн бармый калды ул. Килененең бәхетеннән көнләште, ярдәм сорап аңа ялынмавы ачуын китерде, син дә малай үстерәсең,ниләр күрерсең әле дип күңеленнән килене белән тиргәште. Газиз баласыннан, алиментка түләргә акчасын кызганып, керемен күрсәтми, эштән-эшкә йөргән үз улына рәнҗеде. Узган гомеренең мәгънәсе калмады, алдагысын уйласы да килмәде, беркемгә кирәкмәгәнлеген тоеп, төренеп, кыймылдамый да көн буе ятты да ятты.

Телефон тавышына теләми генә күзләрен ачты. Килене икәнен күреп, бер-бер хәл булмаганмы дип, йөрәге кысып алды. «Сәнгать мәктәбенә барганда улымны эт талаган, дәваханәдә, реанимациядә», — диде килене. Бар үпкәләрен онытып, сикереп торды да, дәваханәгә йөгерде ана. «Кемнән туганга бала гаепле ме, кемнән үч алырга уйладың син, бернигә карамый, үз баланны караган кебек тәрбияләшергә тиешсең син оныгыңны. Беркөнне бармый калдың... Исән генә булса ярар иде».

Күз яшьләренә төелгән ике ана реанимация ишек төбендә түземсезлек белән табиб чыкканын көтәләр. Язмышларына буйсынып, иңнәрендә аталар йөге, аталар бурычы күтәргән бу ике ана күпме генә көтсәләр дә, ишектә баланың әтисе күренмәде...

## ҖЫР БЕЛӘН ЮРАЛГАН БӘХЕТЕМ

Радиоалгычтан күңелем түренә үтеп, җанымны телгәләп таныш моң агыла.

Җырның җыртыгы юк дисәләрдә, һәр заманның үз җыры, үз моңы, үз тамашачысы бар. Әлеге җыр минем яшьлегемдә күп тапкырлар кабатланып, халык теленнән төшми җырланса да, күптән инде ретро җырга әйләнеп, сирәк башкарыла. Хисләремә бирелеп җырчыга ияреп сүзләрен кабатлыйм: «Әйткән идең, әгәр сөя калсаң...»

...Укуымның соңгы елы, дипломымны яклап, туган ягыма эшкә кайтып китәргә тиешмен. Күнегелгән шәһәр тормышын, тулай торагымны, иптәшләремне, дус егетемне калдырып кайтып китү читен тоелса да, алда көткән планнар, туган туфрагым ниндидер өмет өстәп тора кебек.

Буш вакытыбызда икәү очрашып серләшергә яраткан тулай торакның кызыл почмагына чакырып алдың син мине. Бик нык дулкынланганга күрәме, мине күрүгә ялкыннар чәчә торган коңгырт күзләрең никтер күзләремә туры карамады бу юлы. «Матурым!» — әйе, син миңа бервакытта да исемем белән эндәшмәдең, гел «матурым» дия идең.

— Аңларга тырыш мине, матурым, аңларга тырыш. Булдыра алсаң, гафу ит, кыскасы, миңа өйләнергә кирәк икән... Мин читтән торып укырга күчеп, авылга кайтып китәм. Мин сине яратам, сине генә яратачакмын, матурым! Минем, безнең балабыз булачак икән — авылдан хат алдым. Беренче майга кайткач классташларым белән яланга ял итәргә чыккан идек, шунда сабакташ кыз белән очраштык, кыскасы, үзең аңлагансыңдыр инде. Ачуланма мине яме, булдыра алсаң, гафу ит!

Синең яшь тулы коңгырт күзләреңә карап, берни аңламаган хәлдә: «Ә мин?» — дия алдым. Көчле кулларың белән кочып алдың да, назлы итеп сыйпап битләремнән үптең.

— Синең белән шундый рәхәт миңа. Телисеңме, бәби тугач, мин аерылышам да синең белән кабат кавышабыз, — дидең, назлавыңны дәвам итеп. Кайдан килгәндер ул көч, җылы кочагыңнан аерылып, сине этеп җибәрдем.

— Юк, кеше бәхете белән бәхетле булып булмый, башта уйларга кирәк иде! — дип күз яшьләремә төелдем.

Икебез ике почмакта бик озак елашып утырдык без. Олылар тормышына аяк баскан ике яшь йөрәк язмыш сынаулары каршында көчсез иде шул. Без үскән чакта бәхет өчен көрәшү дигән төшенчә дә юк иде булса кирәк, бәлки без, ваемсыз авыл балалары, аны аңлап та бетермәгәнбездер. Үзеңдә көч табып, син минем яныма килдең.

— Әйдә дусларча аерылышыйк булмаса, хәзер берни үзгәртеп булмый инде. Мин сиңа фотомны алып килдем, син дә миңа бирерсең, сагынганда карап юанырмын. Әгәр дә син үзегезнең районга кайтып урнашсаң, аралар ерак, бәлки без башка күрешмәбез дә. Истәлеккә бер-беребезгә яратып тыңлаган җырларыбызны бүләк итик, ул җырларны тыңлаган саен бер-беребезне искә төшереп, яшьлек мәхәббәтебезне искә алырбыз, — дидең.

Елый-елый, язмышыма буйсынып, син истәлеккә бүләк итеп калдырган җырдагы кебек «нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә, әйтерсең дә синең дәвамга» дигән кешегә тормышка чыгып, өч бала үстердем мин. Ачы язмыш җилләреннән, гайбәт сүзләрдән киң күкрәгенә

кысып «минем матурым» дип саклады хәләлем мине. Бик бәхетле булдым мин синең җыр белән юраган язмышымда: сөйдем-сөелдем, кирәк булдым, терәк булдым. Бөреләнеп кенә килгән саф сөю хисләремне җиргә салып таптасаң да, туачак сабыең хакынадыр, мин сиңа үпкә саклый алмадым. Киресенчә, рәнҗетелгән мәхәббәтем минем язмышымда маяк булды. Сикәлтәле сукмаклардан узганда, туры юл якын булса да, аннан үтми, урап үтәр идем. Якыннарымны хәсрәт, борчылу, яисә мәңгелек югалтулардан сакладым. Фотолар актарганда синең сурәтең килеп чыкса, ихлас елмаеп рәхмәт әйттем сиңа.

Күпме сулар акты, олы язмыш юллары үтеп, дәү әни, дәү әти булдык хәзер. Син юраган язмыш юлымда бер генә тапкыр да очратмадым үзеңне. Шунысы үкенечле, үзем сиңа истәлеккә бүләк иткән җырымны хәтерләмим. Мин яраткан җырым белән юралган язмыш сиңа бәхет китерә алдымы икән? Ә моң агыла да агыла...

## ТУГАН ТУФРАГЫМА СӘЯХӘТ
### (ИСКЕ ӘТКҮЛГӘ)

Бик сагындым туган авылымны,
Эчем тулды серле моңнарга.
Барыйм әле туган туфрагыма,
Өянкеләр җырын тыңларга.

Аткүл күлем! Син дә исәнсеңме?
Авылкаең күптән… күченде.
Истәлеккә тополь, өянкеләр куеп,
Язмышына ул бит буйсынды.

Ул язмышның миндә бер баласы
Торам басып, таныш сукмакта.
Кара җирне ярып, өтеп кергән
Чатнап торган кызу кояшта!

Иркәлиләр бәбкә үләннәре, тәпиемне
Бәрхет кебек, сыйпыйм иелеп.
Як-ягыма каранамын үзем,
Килмәгәнме, тилгән сизенеп…

Кара әле, минем әрекмәнем!
Мин үскәндә син дә үстеңме!?
Басу капкасыннан килеп үтәрләр дип,
Урыныңнан күчми көттеңме?!

Әнкәемнең идән себергәнен исләп,
Күзләремнән бөртек яшь тама
Әремнәрем миңа яшел яулык болгап,
Хуш исләрен сибеп хушлана.

Кычытканнар били нигезләрне,
Үтеп булмый алга-арткада.
Ачлыкларда күпме гомер өзелмәде
КЫЧЫТКАНЫМ!
ЮА белән синең аркада!

АЛАБУТА, дускай, нигә моңсуландың әле
Онытмадым сине туганым.
Мөмкин булса санап бирер идем
Күпме гомер сынмый калганын.

Карт каеннар бөгелә-сыгыла шаулый:
«Монда синең авылың билгесе,
Дога сорый, барча әрвахларың
Зират кыл, адәм баласы!»

Агыйделем минем, мин бит синең кызың,
Килдем сине өзелеп сагынып.
Атларлыкта хәлем калмас иде,
Чиксез суларыңда коенып.

Тавыш-тынсыз гына мин тезләндем,
Сипкелемә охшаш комыма.
Куанышып уйнар, кызыныр идек
Кайттым гамьсез балачагыма.

Барысында барлап чыктым дисәм,
Калган икән минем чүмгәлем
Үзем кадәр әтием итекләрен юып,
Хәтерлим чак сүрәп менгәнем.

Шундый газиз туган туфраккаем,
Син бит безгә гомер биргәнсең.

Боекмачы ташлап киттеләр дип,
Гаепне дә бездән күрмә син.

Анам күргән кебек рәхәт булды,
Илһам алдым туган җиремнән.
Рәхмәт әйтеп кайтып китим дисәм,
Идел җиле сыйпый иңемнән!

## ӘТКҮЛЕМ — АВЫЛЫМ УРЫНЫ

Караш җитмәс энҗе ап-ак ялан,
Монда минем авылым урыны.
Безне озатып калган өянкеләр генә,
Әллә юксынудан инде корыды.

Әйтеп булмас зур бер сагыш,
Саклана гел күңелем түрендә.
Бала чагымдагы энҗе ап-ак авыл
Гом(е)рем буе йөрәк түрендә.

Бик күпләргә сагыш китерде ул,
Туган туфрак, нигез югалту.
Еллар үткән саен тик яңара гына
Авылымны уйлап, сагынып ярату.

Ап-ак карлы, салкын, озын кышны
Мин эзләдем туган җиремнән.
Исләремә төшеп балачагым
Буем җитмәс талга үреләм.

Бу җирләрдә таллар булмас иде,
Без киткәчтен алар үскәндер,

Агач чана-чаңгыларда шуып,
Тәгәри-тәгәри монда үскәнмен!

Тирә ягым күзләп алдым да мин,
Яшьлегемнең эзен эзләдем.
Юк, тапмадым — күп вакытлар узган,
Еллар юган гомер эзләрен.

Караш җитмәс энҗе ап-ак ялан,
Якташларның нигез урыны.
Моңаймачы сагынып, нигезем ташы,
Еламачы, рәнҗеп, авылым урыны!

## САГЫНАМЫН — ТУГАН ТУФРАК

Сукмаклары бик күп үтәр өчен,
Тик югалган тәпи эзләрем.
Бала чагым узган авылыма
Алып килде гомер көзләрем.

Бу урында кендек каным тамган,
Ишек алда тәпи киткәнмен.
Карлыганга киткән әнкәемне,
Читәннәргә менеп көткәнмен.

Таба алмыйм бикле ишегемне,
Капкалар да инде юк күптән,
Чәчәкләрен болгап, хуш исләрен сибеп,
Нигеземдә көткән кычыткан.

Көянтәләп узган сукмагымны,
Сулар юып күптән юк иткән,

Кер чайкаган тирәкләрем кипкән,
Төшләремә кереп зинкеткән.

Сагынамын сине, туган туфрак,
Гомеремнең газиз мизгелен!
Әгәр мөмкин булса кайтарырга —
Сорар идем, бары — бер көнен!

## ДУСЛЫК СӘФӘРЕ

Башкортстан җыя изгеләрне,
Хаҗ кылырга изге Болгарга.
Әби-бабасыннан калган тарихына
Туфрагында дога юлларга.

Тарихымны барлап,
Һәр сукмагын узам.
Дога кылам, сорыйм тынычлык
Татар белән башкорт милләтенә
Намаз укып телим чын дуслык.

Дуслар табам, дуслык сәфәрендә,
Гыйбрәт алам дөрес яшәргә.
Талантлылар белән уртак сер алышам,
Иҗат белән кайнап яшәргә.

Ак теплоход, ак нияткә төреп,
Агыйделне узды, йөзде Чулманны.
Киң Иделне күптән биләде.
Туганлыкка якты өмет баглап,
Дуслык күперендә тибрәлде!

## МИН — ХАТЫН-КЫЗ

Мин — хатын-кыз,
Сөясем килә, сөеләсем.
Иң бәхетле минутымда
Йолдызга үреләсем.

Җиһан биләп, йолдыз эзләп,
Кинәнеп яратасым.
Җиргә төшкәч сабыр гына
Көтәсем, таң атасын…

Иртәнге таң кояшыдай
Галәмне җылытасым.
Мәрхәмәтле ана булып,
Куанып юатасым.

Гади генә язмыш белән
Килә гомер итәсем.
Чәчкәләрдәй шиңми генә
Картлыгымны көтәсем.

## СИН УЯТМА

Син уятма, йоклый йөрәккәем,
Чәчмә миңа сөю нурларын.
Гомер узган, күперчекләр сынган,
Тетрәндермә йөрәк кылларын.

Син уятма, йоклый йөрәккәем,
Яраланган тормыш йөгеннән.

Фани белән бакый арасында
Сөю җебе күптән өзелгән.

Син уятма, йоклый йөрәккәем,
Хыянәттән кинәт сүнгәнме?
Сөю шәмен яндырулар авыр,
Ялгызлыктан җаным сулганмы?

Син уятма, йоклый йөрәккәем,
Бу яшемдә сөю — куркыныч.
Өмет сукмакларым буталса да,
Киләчәгем өчен мин тыныч.



# САМАТОВА
## САРИЯ ШАЙМАРДАНОВНА

Саматова Сария Шаймардановна родилась в 1952 году в деревне Новый Татыш Краснокамского района. После окончания средней школы трудовую биографию начала на стройке в городе Нефтекамске и там проработала всю жизнь. . Оттуда же ушла на заслуженный отдых. Вырастила пятерых детей. Творческий дебют состоялся в 1985 году. Печаталась в местной газете, состояла в литературном объединении. В настоящее время живет в городе Агидель, пишет на татарском и русском языках. Член литературного объединения «Агидельские родники».

## ЯШИМ ӘЛЕ

Гомер бик тиз үтә, еллар китә,
Картмын димим, җәфа чикмимен.
Оҗмах түрләрендә яшим әле,
Бернәрсәгә мохтаҗ түгел мин.

Балаларым башлы-күзле булды,
Гөрләп бара тормыш юллары.
Туа тора, үсә тора, белем алып,
Матур кызлар, батыр уллары.

Һәрчак төяп килә балаларым,
Бүләкләрен, күчтәнәчләрен.
«Нәнәй-нәнәй», — диеп кенә тора,
Оныкларым — бәләкәчләрем.

Килсәм — затлы кунак, китсәм — ерак,
Үз көнемне үзем күрәм мин.
Туганнарым һәм дә дусларым күп,
Бу дөньяда ялгыз түгелмен.

Үткәннәргә үкенмимен әле,
Рәхмәтлемен исән-саулыкка.
Гомер ике килми, яшим әле
Сөенеп кенә булган байлыкка.

* * *

Без икәүләп тормыш юлына чыктык,
Син барасың алдан иркен юл ярып.
Мин атлыймын бары синең эздән,
Синең йөрәгеңнән көч һәм дәрт алып.

Ярый әле, бәхетемә син очрадың,
Аңым, җаным-тәнем сине теләде.
Синең ышыгында миңа тыныч булды,
Язмышымда үкенечләр булмады.

Өлкән-олпат баһадирлар сыны синдә,
Мәшһүр олатайлар рухы акылы.
Буыннардан килгән илһам көче безне,
Киләчәккә дәшә еллар аркылы.

Мин карыйм да сиңа, сокланамын,
Күзләреңдә чагыла көчле омтылыш.
Максатларга ирешү нәтиҗәсе булып,
Тик бәхеткә алып барсын бу тормыш.

* * *

Мин гашыйкмын!
Тормыш даулап аһәң каккан,
Тыпырдатып тәпи баскан
Газиз җиремә.

Мин гашыйкмын!
Киләчәккә юлны ачкан,
Шунда бәхетемне тапкан
Туган илемә.

Мин гашыйкмын!
Мәшһүр бабалардан калган,
Нәсел данын саклый алган
Халкым теленә.

Мин гашыйкмын!
Чиксез тарафларга ашкан,
Сихри киңлекләргә дәшкән
Зәңгәр күгемә.

Мин гашыйкмын!
Кайчак зәһәрләнеп даулап,
Кайчак чәчтән йомшак сыйпап
Искән җилемә.

Мин гашыйкмын!
Илаһи исләр-төсләр сайлап,
Җирнең гүзәллеген җыйнап
Үскән гөлемә.

Мин гашыйкмын!
Бер кашыктан ризык капкан,
Урын-җирен уртаклашкан
Хәләл җефетемә.

Мин гашыйкмын!
Туган-тумачасын санлап,
Тормыш ямен-тәмен данлап
Яшәүченең үзенә.

## БӘХЕТЕМ МИНЕМ

Бер елмаеп күзләремә бактың,
Иркә сыйпап сөйдең иңемнән.
Язмышымны юрап, фәрештәдәй,
Бик хуп килдең минем күңелемә.

Әле татылмаган изге хисләр булып,
Сихри ләззәт җанга сарылды.
Йөрәгемдә сүнәр-сүнмәс очкын яна иде,
Ялкын булды — дөрләп кабынды.

Булмышымны чорный чиксез бәхет,
Иркәләнеп сыенам җылы куенына.
Сагышлардан арыган җан ярасы,
Үз дәвасын табып, сөеп юана.

Башыма килә бары якты уйлар,
Нәфис сүзләр генә килә телемә.
Мәңге сайрар сандугачым кунды,
Шиңеп барган ялгыз гөлемә.

Пар канатым җилпеп, дарьяларны кичеп,
Ашкынып, ярсып килә очасым.
«Мин бәхетле!» — диеп оран салып,
Бар Галәмне килә кочасым.

Изге хисләр гомерлеккә булсын инде,
Югалтулар әрнетмәсен иде күңелне.
Хозурланып, наздан иркәләнеп,
Үткәрергә язсын булган гомерне.

## ЯҢА ЕЛГА КЕРЕР АЛДЫННАН

Яңа елга керер алдыннан
Ак шәлемне алып ябынам.
Ак кар кебек ап-ак күңелемнең
Якты өметләре кабынган.

Яңа елга керер алдыннан
Сый-хөрмәтләр китми табыннан.
Яңа елда табын тулып торсын,
Авыз итеп калыйк барыннан.

Яңа елга керер алдыннан
Кыш бабайның ап-ак карыннан
Шатлыкларны кушып ясыйк та —
Шуыйк бергә бәхет тавыннан.

Яңа елга керер алдыннан
Барлык дөнья ак шәл ябынган.
Ак кар кебек ап-ак күңелләрнең
Якты өметләре кабынган.



# СУЛЕЙМАНОВА
## МАНЗИЛЯ ТУХВАТУЛЛОВНА

Сулейманова Манзиля Тухватулловна родилась в 1966 году 27 февраля в деревне Азово Архангельского района Республики Башкортостан. Училась в г. Уфе в башкирской гимназии №1 им. Рами Гарипова. Окончила Башкирский государственный университет (г. Уфа), факультет башкирской филологии и журналистики. Много лет работала учителем башкирского языка и литературы в г. Агидель. Пишет и исполняет кубаиры. Дипломант Межрегионального литературно-поэтического фестиваля-конкурса устного творчества «Ата-бабалар ауазы» — «Зов предков».

## ҠАЙТЫР ЕРЕМ

Тәбиғәттең йәмле ҡосағында,
Йылға буйҙарында үҫтек беҙ.
Бәхет эҙләп сығып киткән саҡта,
Моңһоу ҡалды тыуған еребеҙ.

*Ҡушымта:*
Күңелдәргә көҙ һағышы тулһа,
Йә өшөтһә яҙмыш бураны —
Һыйындыра тыуған йорт йылыһы,
Йөрәгемдең баҫа яраһын.

Томбойоҡтар күлдә әкрен генә
Ай нурына төрөнөп йомола.
Наҙлы тынлыҡ минең күңелемә
Дауа булыр кеүек тойола.

Татлыраҡ та ине шишмә һыуы,
Серлерәк тә ине һуҡмаҡтар.
Йылдар үткән һайын үҙенә тарта,
